КЫЙММӘТЛЕ КӨПЧӘК

Бүген машина бәясе кыш тота торган түгел

> 5

БӘБИ КӨТКӘНДӘ

Районнардагы бала тудыру йортлары ник ябыла?

> 6

САЛАВАТ ФӘТХЕТДИНОВ:

«Бер оятсызны җиңү өчен, кимендә ике акыллы кеше кирәк»

> 18–19

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 190 (28963) | Җомга | 23 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

БЕЗГӘ КИЛЕП КҮРЕГЕЗ!

ТАТАРСТАНДА КАЙДА ҺӘМ НИЧЕК ЯЛ ИТӘРГӘ?

«Каян килгән бу халык?» дип аптырыйсы түгел. Кышкы яллар җитәрәк, Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитетында шулай дип кисәтеп куйдылар. Битлекле-чикләүле 2020 елда кышкы каникул чорында республикага 152 мең кунак килгән иде. 2021 елда 140 меңләп кеше сәяхәт итү өчен Татарстан һәм аның башкаласын сайлаган. Быел исә кышкы ялларда 180 мең кеше килер дип көтәләр. Гаҗәпләнерлек түгел шикелле. Әллә ни чикләүләр булмаса да, чит илләргә юллар ябык бит. Әмма сәяхәт итү теләге чиксез. Диңгезе булмаган, әмма бай тарихлы һәм гаять кунакчыл Татарстан нәрсә белән шаккатырырга сәләтле? Республиканың үзебез өчен дә, кунаклар өчен дә кызыклы урыннарын «ВТ» барлады.

> 16

Ишетми калмагыз

Россия оборона министры Сергей Шойгу Россиядә хәрби хезмәткә чакыру яшен акрынлап 18дән 21 яшькә кадәр, ә армиягә чакыруның чик яшен 30 яшькә җиткерергә тәкъдим итте. Дәүләт Думасында министр тәкъдимен хуплыйлар. Думаның Оборона комитеты башлыгы Андрей Картаполов әйтүенчә, депутатлар бу җәһәттән законга үзгәрешләр кертергә әзер. Әмма әлеге мәсьәлә буенча Оборона министрлыгыннан рәсми тәкъдимнәр көтәргә кирәк әле. Ведомство аларны тиз генә әзерләп җибәргән очракта, закон киләсе елда кабул ителергә мөмкин.

Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин имзалаган карарда республикада транспорт чараларына техник тикшерү уздыру бәясенең чикләре билгеләнгән. Киләсе елның 1 гыйнварыннан бу эш 80 процентка диярлек кыйммәтләнә.

М1 категориясендәге транспорт (җиңел машиналар) өчен техник карау үткәрүгә түләүнең чик күләме – 913 сум, М2 һәм М3 категорияләре өчен (автобус, троллейбус, махсус пассажир транспорты) 1563 һәм 1888 сум тәшкил итәчәк. Йөк машиналарына техосмотр уздыру, төренә карап, 999 сумнан 1966 сумга җитәчәк. Мотоцикллар, мопед, квадроцикллар һ.б. карау бәясе 321 сумга төшәчәк. Бәяләрне Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты контрольдә тотачак.

Ел башыннан бирле республиканың мәгълүмат киңлегендә 29 фейк ачыкланган. Күпчелеге махсус хәрби операция һәм өлешчә мобилизациягә бәйле. Татарстан Төбәк белән идарә итү үзәге мәгълүматларына караганда, март аенда интернетта, янәсе, озакламый илдә хәрби хәл кертеләчәк, шуңа күрә күпләп азык-төлек сатып алырга кирәк, дигән чакырулар белән тулы хәбәрләр таратыла башлаган. Декабрьдә исә социаль челтәрләр, имештер, мобилизацияләнүчеләрнең, хәрби хезмәткә әзерләү үзәге капкасын җимереп, аннан качулары турында хәбәрләр белән тулган. Татарстанда массакүләм мәгълүмат чаралары, социаль челтәрләр һәм мессенджерларда ялган мәгълүматтан торган хәбәрләрнең гомуми саны 24 меңнән артып киткән. Алар 17,3 миллионнан артыграк карау, 207 мең «лайк», 84 меңнән күбрәк репост һәм 34 мең чамасы фикер җыйган. Тиешле ведомстволар ялган хәбәрләрнең һәммәсен дә тиз генә кире кагып, үзләренең аңлатмаларын биргән.

Бу көннәрдә Татарстанда җылытып, тәүлеклек уртача температура нормадан 8–10 градуска артып китәчәк. Синоптиклар фаразына караганда, шимбә-якшәмбедә республикада җепшек кар, яңгыр, буран, секундына 15–17 метр тизлектә көньяк-көнбатыштан көчле җил, юлларда бозлавык булачак. Шимбә – 24 декабрьдә тәүлек буе һава температурасының –2…+3 чикләрендә тирбәлүе көтелә. Якшәмбе – 25 декабрьдә көндез +1…–4, төнлә –8 градуска кадәр.

Башлангыч мәгълүматларга караганда, киләсе атна башында явым-төшем акрынлап кимеп, һава температурасы шактый ук төшәчәк.

АЛГЫ СЫЗЫКТА

Авыл җирлекләренә бирелә торган грант күләме 1,5 млн сумнан 2 млн сумга кадәр артачак. Казанның «Корстон» кунакханә-сәүдә күңел ачу комплексында «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясенең XVII съездында әнә шундый күңелле хәбәрне алкышларга күмделәр.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Теләкләр чыршысы» проектында катнашты. Ул Казанда яшәүче ике баланың теләген үтәячәк. Аларның берсе – балалар радиосын барып күрергә, икенчесе исә «акыллы колонка»лы булу турында хыяллана. «Балалардан елдан-ел күбрәк хатлар алабыз, аларның хыялларын тормышка ашырырга тырышабыз. Яңа елга кадәр вакыт бар әле!» – дип язган Рөстәм Миңнеханов үзенең телеграм-каналында.
Хәйрия акциясендә Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә катнашты. 9 яшьлек Зифа Вәлиева Казанда Президент чыршысында булырга хыяллана икән. 13 яшьлек Азалиянең кинолог булып карыйсы килә.

Утырышта авылда эш урыннарын булдыру, авыл территорияләрен төзекләндерү, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү, халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү, үзара салым программасын гамәлгә ашыру турында да сөйләделәр. Билгеле, телдән-телгә йөргән мәсьәләләр дә игътибар үзәгендә булды. Шулай булмыйни, көн кадагында торган хәбәрләрне җиткерү, ир-атларга чакыру кәгазьләрен тапшыру, мобилизацияләнгәннәрнең якыннарының хәлен белешү, кирәк булганда, ярдәм кулы сузу да, махсус хәрби операциядә катнашучы егетләребезгә гуманитар ярдәм оештырып җибәрү кебек үтә җаваплы һәм тынгысыз бурычлар да район һәм җирле үзидарә башлыклары җилкәсенә төште бит.

Төп доклад белән чыгыш ясаган Әгъзам Гобәйдуллин җирлекләрдәге, хуҗалык итүнең кече формаларына бирелә торган дәүләт ярдәмнәре турында да искә төшерде. Әйтик, «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» федераль дәүләт программасын гамәлгә ашыруга 2022 елда 2 млрд сумнан артык акча тотылган.

– Әлеге программага ихтыяҗ зур, алдагы елларда да шулай уңышлы эшләр дип ышанып калабыз, – диде Әгъзам Гобәйдуллин. – Шул ук вакытта авыл хуҗалыгында кече һәм урта бизнес җитештерүчеләренә бик авыр туры килә. Алар ягулык, электр энергиясе, ашлама бәяләре арту шартларында эшләргә мәҗбүр. Шуңа күрә авыл халкының эшлекле активлыгын арттырыр өчен өстәмә чаралар кирәк. Дәүләт Думасы депутатларына мөрәҗәгать итеп, икътисадый ярдәм чараларын карауны сорыйбыз.

Әгъзам Гобәйдуллин фикеренчә, үзәктән читтәрәк урнашкан авылларда авыл хуҗалыгы тармагын җәелдерү өчен халыкка һәм инвесторларга җир участокларын сату уздырмыйча гына бирсәләр, субсидияләр алганда документ эшләре җиңеләйтелсә, йорт салыр өчен җир участокларын алу мәшәкате дә кимрәк булса, авылга яшьләр күбрәк кайтыр һәм эш урыннары да артыр иде.

Утырышта кадрлар мәсьәләсе дә күтәрелде. Әгъзам Гобәйдуллин сүзләре буенча, авыл һәм шәһәр җирлекләре башлыкларының эш урыннарын еш алыштыруы күзәтелә.

– Сайлаулардан соң үткән ике ел эчендә 144 кеше алышынды. Күп тә түгел кебек. Әмма сайлаулар яңарак кына узды бит, шуңа да сорау туа. Алар ике елдан да кимрәк эшләрмен дигән ният белән килмәгәннәр бит инде. Әмма төрле сәбәпләр аркасында китәргә мәҗбүр булалар. Шуңа күрә җаваплы барлык җитәкчеләргә мөрәҗәгать итәсем килә: муниципалитет башлыклары составына, муниципаль хезмәткәрләргә карата игътибарлы булсагыз иде. Тәҗрибәле кадрлар белән бергә яңа яшь белгечләргә дә игътибар итү кирәк, – диде ул.

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре, халык белән эшләгәндә, алгы сызыкта торалар һәм иң кискен мәсьәләләрне хәл итәләр, диде Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов. Ул хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә, аеруча һәлак булган сугышчыларның гаиләләренә аерым игътибар бирергә кушты. Бу юнәлештә эш барлык шәһәр һәм районнарда оештырылган. Аның сүзләре буенча, быел республикада 44 республика программасы, 8 илкүләм проект, 6 дәүләт программасы, шулай ук программадан тыш чаралар һәм инфраструктурага бәйле проектлар кысаларында 4,2 меңнән артык объект төзелгән һәм капиталь ремонтланган.

– Бернәрсәгә дә карамастан, без алдыбызга Татарстанның социаль-икътисадый үсеш темпларын саклау бурычын куябыз. 2023 елда барлык республика программаларын саклап калу турында карар кабул ителде, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Шул ук вакытта икътисад өлкәсендәге бурычлар белән бергә, республикада тотрыклылыкны саклау төп бурычларның берсе булып тора.

– Бу эштә аерым җаваплылык, хөрмәтле муниципаль берәмлек башлыклары, сезгә йөкләнә, – дип мөрәҗәгать итте ул. – Сүз, барыннан да элек, халык белән эшләү турында бара. Сез кешеләрнең кәефен барыннан да элек тоясыз, урыннардагы хәлне, барлык проблемалы сорауларны белеп торасыз. Халыкның активлыгы арта. Аларга игътибар һәм теләктәшлек күрсәтү, кешеләргә ярдәм итү мөһим. Бу исә җәмгыятьтә үзара ышаныч һәм тотрыклылык дәрәҗәсен ныгытырга тиеш.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТИКТОМАЛДАН АКЧА ТАРАТМЫЙЛАР

Президент Рөстәм Миңнеханов Татарстан инвесторлары клубы эшенең еллык йомгакларына багышланган чарада катнашты. Очрашу барышында ул җиткергән төп фикерләрне тәкъдим итәбез.

Минем уйлавымча, бүген без инновацияләр һәм яңа технологияләр өлкәсендә көндәшлеккә сәләтле була алабыз. Хакимиятнең төп бурычы ул – халыкның тормыш дәрәҗәсен яхшырту. Җир шарында булган бөтен әйбернең өчтән бер өлеше бездә (Россиядә. – **Ред.**) җитештерелә. Безне ник ятрабып бетермиләр? Яратмыйлар, дип әйтәсем килми. Чөнки бездә башкаларда булмаган әйберләр күп. Без, әлбәттә, алар өчен көрәшәчәкбез.

Татарстандагы яңа сәнәгать мәйданнары – Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре, махсус икътисадый зоналар республикадагы барлык сәнәгать продукциясенең 10 процентын җитештерә. Бу бик күп. Без инфраструктура һәм система булдырдык. Ул эшли. Моны дәүләт түгел (инвестиция проектларын тормышка ашыру турында. – **Ред.**), ә инвесторлар бурычка алган акчага һәм үз хисабына тормышка ашырды. Минем уйлавымча, хакимият тиешле шартлар тудырырга тиеш. Ә акча тарату, яхшы булып күренергә тырышу – ялгыш юл. Без ярдәмгә чыннан да мохтаҗларга гына булышырга тиеш. Рәттән китеп түгел. Болай эшләү «тагын бирерләр әле» дигән ялгыш фикер уята.

Ел азагына кадәр Татарстанда 1,4 триллион сум салым җыеп алынырга тиеш. Шуның 400 миллион сумга якыны республикага туры килә, ә 1 триллион сум акча федераль үзәккә китәчәк. Татарстан – ил күләмендә зур салым түләүчеләрнең берсе. Бу дөрес тә. Ил алдында иминлек, оборона бурычы тора. Бигрәк тә бүген: кем фронтта, кем тылда – барыбыздан да ярдәм таләп ителә.

Килеп чыккан хәлләр бездән логистиканы үзгәртү, төрле карарлар кабул итү һәм технологияләрдән файдалану мөмкинлеген булдыруны таләп итә. Әйе, без технологияләр эзлибез. Бәлки, безгә кайчак үзебезгә утырып уйларга кирәктер. Безнең бабаларыбыз атом бомбасы, ракеталар, иң яхшы очкычлар уйлап тапкан бит. Моның өчен Россия дәүләтенең акыл дәрәҗәсе һәм мөмкинлекләре җитәрлек дип уйлыйм. Билгеле, күпмедер вакыт базарлар белән кыенлыклар кичерәчәкбез, әмма безне көткән якка таба карарга кирәк.

БӘЙРӘМ ЯНӘШӘ!

ТАТАРСТАННАН ЛИСИЧАНСК БАЛАЛАРЫНА ЯҢА ЕЛ КҮЧТӘНӘЧЛӘРЕ ОЗАТТЫЛАР

Алар да сөенсен! Тиздән Луганск Халык Республикасының Лисичанск шәһәрендә яшәүче балаларга Яңа ел бүләкләре төялгән машиналар барып җитәчәк. «Ярдәм янәшә!» хәрәкәтенең бәйрәм алды акциясенә югары уку йортлары, төрле район вәкилләре, журналистлар кушылды.

Тәм-томнар, уенчыклар, китаплар, уку кирәк-яраклары – бәйрәм күчтәнәчләре бөтен Татарстаннан дистәләгән тонна җыелган. Татарстанның яшьләр эшләре министры урынбасары Алла Кондратьева сүзләренчә, елның иң тылсымлы бәйрәме алдыннан бөтен республика халкы, берләшеп, Лисичанск балаларына Яңа ел кәефе бүләк итәргә ниятләгән.

– Шуңа да без балаларга бәйрәм рухы бүләк итә торган әйберләр – баллы күчтәнәч, Яңа ел өстәленә ризыклар, уенчыклар һәм башкаларны тупладык. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән мәктәп укучылары өчен җылы спорт киемнәре тектердек, – дип сөйләде ул.

Республика журналистлары да, шул исәптән «ВТ» да читтә калмады. Пластилин, буяу, карандаш, фломастер җыелмалары, кулдан ясалган әйберләр, төрле яшьтәге балалар өчен китаплар һәм уенчыклар тутырылган барлыгы 38 бүләк тартмасы җыелды.

Ә Казан вузлары күчтәнәчләрнең баллы өлеше өчен җаваплы булган – балалар өчен ике меңләп данә татлы Яңа ел бүләге әзерләнгән.

– Безнең барлык уку йортлары белән ургак чат бар. Лисичанск балаларына ярдәм итик, дигәч, берәү дә битараф калмады. Бер көн эчендә ике меңләп Яңа ел бүләге җыйдык, – диде Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университетының административ эш һәм социаль үсеш буенча проректоры Наталья Гречанникова.

Татарстаннан Лисичанскига җәмгысы 600 тоннага якын гуманитар ярдәм җибәрелгән. Әмма моның белән генә туктарга җыенган кеше юк. Сүз уңаеннан, гуманитар ярдәм җыю эшенә теләгән һәркем кушыла ала. Тулырак мәгълүматны хәрәкәтнең рәсми сайтыннан табарга мөмкин.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ӘНИСЕ АҢЛАСА, БАЛАСЫ ТЫҢЛАР

28 декабрьдән балалар кышкы каникулга китәчәк. Ялдагы кагыйдәләрне искә төшереп, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашында әти-әниләр җыелышы узды. Онлайн рәвештә узган чарада белгечләр каникулда әти-әниләрне балаларга карата аеруча игътибарлы булырга өндәде.

– Мәктәптә белем һәм тәрбия бергә бирелә. Әмма тәрбия мәсьәләсендә төп җаваплылык – әти-әниләрдә, моның нигезе гаиләдә салына. 2020 елда министрлык каршында Әти-әниләр советы булдырдык. Ул республикадагы барлык әти-әниләр комитетларын берләштерә, аларны борчыган сорауларны хәл итәргә булыша, – диде Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин, аларның активлыгын билгеләп.

Фәрит Мөхәммәтшин да тәрбия өчен әти-әниләрнең җаваплы булуын әйтте. «Өйдә тыныч булмаса, әти-әнинең эшендә дә нәтиҗә булмый. Бу балалар психикасына да тәэсир итә. Гаилә кору авыр түгел, аны саклау авыр», – диде парламент җитәкчесе. Ул әти-әниләре аерылышырга җыенган балаларны аеруча игътибарда тотарга, гаилә таркалмасын өчен, кулдан килгәннең барысын да эшләргә кирәклеген әйтте. Ул «Мөһим сөйләшү» дәресләрендә гаилә кыйммәтләре турында сөйләшергә тәкъдим итте. Әти-әниләр комитетларына да тәрбия эшен көчәйтергә кушты.

Министрлык каршындагы Әти-әниләр советы рәисе урынбасары Елена Кружкова бүген әти-әниләргә бәйле проблемаларны атады.

– Бөтен әти-әниләр дә гаилә кыйммәтләрен аңлап бетерми. Һәр гаиләдә ышаныч, җаваплылык булу мөһим. Безнең чараларда әби-бабайлар да катнаша. Нәрсә ул гаилә? Бала бу сорауга дөрес җавапны белергә тиеш, – дип сөйләде ул. – Быел барлыгы 2908 тикшерү уздырдык. Мәктәп ашханәләренә дә йөрибез. Балалар ашамый дип зарланган әти-әниләрнең 90 процентының өендә туклану культурасы юк. Безнең күзәтүләр буенча, балалар Европа ризыкларына өстенлек бирә.

Балаларны тәрбияләү буенча 2473 әти-әнинең бушлай киңәш алуын да әйтте ул. Монда проблемалар да ачыкланган. «Әти-әниләр психолог кирәклеген аңламый. Теләсә кайсы сорау буенча мөрәҗәгать итсеннәр иде. Гомумән, гаиләдә аралашу булганда гына рәхәт булачак», – диде ул.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстандагы Баш идарәсе вәкиле Айрат Садыйков, балалар ялларга киткәнче, тагын бер кат янгын куркынычсызлыгын искә төшерде. Быел өч баланың гомере утта өзелгән. Белгеч моның сәбәбен өлкәннәрнең игътибары җитмәүдә күрә.

– Балаларны күпме генә мөстәкыйль дип санасак та, үзләрен генә калдырмагыз. Әгәр өйдә электр җиһазлары сүнеп-кабынып ала икән, белгеч чакырыгыз, ватык розеткаларны төзәтегез, – дип кисәтте ул олыларны.

Татарстанның Дәүләт автоинспекциясе башлыгы урынбасары Дамир Бикмөхәммәтов юлда игътибарлы булырга киңәш итте. Быел балалар катнашында 387 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән. Анда 409 бала имгәнгән, 11енең гомере өзелгән. Җәяүле балаларга кагылышлы 180 фаҗига килеп чыккан. 182се төрле җәрәхәтләр алса, икесе үлгән. Белгеч әти-әниләргә юл кагыйдәләре турында балаларга көн саен сөйләп торырга, яктылык кайтаручы элементлары булган киемнәр кидерергә кушты.

Сәрия МИФТАХОВА

Теманың дәвамы 15 нче биттә >

Партия эшләре

БЫЕЛГА МЕНӘ ШУЛАЙ

Казанда «Бердәм Россия» партиясенең төбәк политсоветы Президиумының йомгаклау утырышы узды. Утырыш кысасында партиянең Татарстандагы бүлеге эшенә йомгак ясалды һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарында депутат берләшмәләре эшен иң яхшы оештыру буенча бәйгедә җиңүчеләр бүләкләнде.

«Бердәм Россия»нең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, утырышны ачып, 2022 елның гади генә булмавын билгеләп үтте.

– Быел, махсус хәрби операция сәбәпле, азат ителгән территорияләргә даими ярдәм күрсәттек, гуманитар йөкләр җибәрдек, Луганск һәм Донецк Халык Республикалары территориясендәге волонтерларыбызга һәм үз ихтыяры белән китүчеләргә ярдәм иттек. Әмма барлык кыенлыкларга карамастан, елны уңышлы тәмамлыйбыз. Әле күптән түгел генә үткәрелгән республика киңәшмәсендә Президент Рөстәм Миңнеханов хакимиятнең барлык тармакларының көйле эшләвен билгеләп үтте. Икътисадка басым шартларында, Президент фикеренчә, ел уңышлы төгәлләнә. Татарстанда барлык проектлар һәм программалар, шул исәптән партиянеке дә, уңышлы тормышка ашырылды. Партия оешмасы сафлары ишәйде, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

«Бердәм Россия»нең Татарстандагы бүлеге Секретаре әйткәнчә, республика «бердәмроссиялеләре» барлык юнәлешләр буенча бердәм эшләде. Фәрит Мөхәммәтшин шулай ук Татарстанда яшәүчеләрнең махсус хәрби операция шартларында бер-берсенә ярдәм итеп килүен билгеләп үтте. Дәүләт Советы Рәисе әйтүенчә, халык мохтаҗларга булышуны дәвам иттерә.

Партиянең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре урынбасары, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Юрий Камалтынов «Бердәм Россия» депутатлары фракциясенең Дәүләт Советындагы эшчәнлеге йомгаклары турында сөйләп үтте. Ул быел фракциянең 10 утырышы, 8 Президиум утырышы үткәрелеп, 32 мәсьәлә каралуын әйтте. Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, фракциянең Дәүләт Советындагы эше нәтиҗәле булган. Парламент башлыгы район һәм шәһәрләрдә фракцияләр эшен көчәйтергә тәкъдим итте.

Утырышта «Бердәм Россия»нең төбәк башкарма комитеты җитәкчесе Марат Сәмигуллин төбәк бүлегенең 2022 елдагы эш планының үтәлүе һәм киләсе елга планны раслау турында сөйләде.

Җиде кат уйлыйсы

Татарстанда «Президент» атамасы урынына исеме җисеменә туры килерлек алмаш сүз эзлиләр. Билгеле булганча, федераль үзәк таләпләре нигезендә киләсе елдан илдә бер генә Президент калырга тиеш. Мөһим сорауга җавап эзләгәндә, Татарстан Дәүләт Советы депутатлары арасында бәхәс чыкты.

Чәршәмбе көнне Дәүләт Советы депутатлары Татарстан Конституциясенә төзәтмәләр кертергә тәкъдим итте. 37 депутат имзалаган документны икенче көнне республика парламентының Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә комитетында тикшерделәр. Комитет рәисе Альберт Хәбибуллин билгеләп үткәнчә, әлеге закон проекты республика законнарын федераль законнарга туры китерү буенча Дәүләт Советы Рәисенең күрсәтмәсе белән төзелгән эшче төркем тарафыннан эшләнгән. Билгеле булганча, республиканың гамәлдәге Конституциясе җиде бүлектән һәм 126 статьядан тора. Депутатлар тәкъдим иткән закон проекты белән 58 статьяны үз эченә алган 6 бүлеккә үзгәрешләр кертелә. Татарстан Конституциясенең 22 нормасын үз көчен югалткан дип танырга тәкъдим ителә.

Альберт Хәбибуллин әйтүенчә, тәкъдим ителгән үзгәрешләрнең шактый өлеше дәүләт хакимияте органнары системасын, аларның вәкаләтләрен, эшчәнлеген һәм аларның үзара хезмәттәшлеген җайга сала торган нигезләмәләрне актуальләштерүне күздә тота.

Әмма аерым игътибарны таләп иткән мәсьәләләр дә бар. Әйтик, закон проектында Татарстанның югары вазыйфаи заты вазыйфасына кандидатка куелган Татарстан Республикасының дәүләт телләрен белү турындагы таләп кире кагыла. Ә республикада дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, республиканың дәүләт учреждениеләрендә Татарстанның дәүләт телләре бертигез дәрәҗәдә кулланыла.

Депутатлар фикеренчә, закон проектында Татарстан җитәкчесе вазыйфасын атаганда, республикада яшәүче халыкларның тарихи һәм милли үзенчәлекләрен исәпкә алу мөмкинлеге кулланылмаган. Ә федераль законда андый мөмкинлек бар. Депутатлар бу мәсьәләгә аерым тукталды. «Миндә закон проектына карата тирән канәгатьсезлек хисе бар, – диде Римма Ратникова. – Без иң югары вазыйфаи затның атамасын республикабызның үзенчәлекләрен исәпкә алып тәкъдим итәргә тиеш. Төрки телләрдән дә алырга була, өстәвенә, хәзерге вакытта без ислам дөньясы илләренә дә юнәлеш тотабыз». Римма Ратникова «Юлбашчы» дигән атаманы тәкъдим итте.

Депутат Марат Галиев – төзәтмәләргә имза куючыларның берсе.

– Россия Конституциясенә үзгәрешләр кертелү сәбәпле, без әзерләгән тәкъдимнәрнең шактый өлеше кабул ителергә мөмкин, дип саныйм. Мин шуңа күрә документны имзаладым. Әмма эш алай җиңел генә хәл ителә торган түгел. «Президент» атамасы турында әйтсәк, бу атаманың кайдан килеп чыкканын искә төшерәсем килә. Президент вазыйфасы гомуми тавыш бирү нәтиҗәсендә барлыкка килде. Тагын бер кат искәртәм: аны 1991 елда халык үзе кертте. Ә халык теләге өстенлеккә ия. Шулай булгач, без аны хәзер ничек итеп тиз генә үзгәртә алабыз соң? Бу мөмкин түгел. Тагын шунысы да бар: республика җитәкчесенең яңа атамасы ике телдә дә аңлаешлы булырга тиеш. Мәсәлән, «Илбашы» дигән тәкъдим белән килешмим. Ярар, аны Балтач районында аңларлар, ә Самара өлкәсендә яшәүчеләргә ничек аңлатабыз? – диде Марат Галиев.

Тәкъдим ителгән закон проекты «федераль үзәк белән килешү нигезендәге мөнәсәбәтләр»не дә исәпкә алмый. «Без Татарстанның Россия составына керүенә бәйле хокукый нигезне бөтенләй шик астына куябыз», – диде Марат Галиев. «Суверенитет» төшенчәсен дә болай гына сызып ташлап булмаячагын әйтте.

Фикер алышу нәтиҗәләре буенча документны әзерләп бетерү карары кабул ителде. Шулай итеп, закон проектын да кире алырга тәкъдим иттеләр. Мәсьәлә турында Дәүләт Советының чираттагы сессиясендә сөйләшәчәкләр.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Әйтеп кенә бактым

«Уау!»

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне телевизордан тапшыру карап утырам. Алып баручы тапшыруга килгәннәргә сораулар бирә. Җаваплар кызыклы, мәгънәле тоелса, тыныч кына, хәтта бераз оялган сыман: «Уау!» – дип хуплап куя. Тапшыруның нинди каналдан барганын, ничек аталганын да әйтмим. Бу татарча тапшыру иде. Нәрсәнедер хуплаганда, «Уау!» – дип куюның максатын аңлап бетермәдем мин. Әллә бу заманнан артта калмаска тырышу микән? Бәлки, акыллы булып күренергә омтылудыр? Әллә бәлки, мин бүгенге яшьләрнең, телевидение телен аңлап бетермимдер? Ни дисәң дә, теге гасыр кешесе бит!

Телеэкраннардан татарча тапшыруларда «покапока!» дип саубуллашуларга күнегеп беттек инде, бу «уау»лары, «сленг»лары нәрсә икән инде? «Сленг» нәрсә ул?» – дип улымнан сораган идем, бер сүз белән: «Жаргон», – диде. Әдәби сөйләм теле тирәсендә буталып йөргән сүзләрне мулдан кулланырга тырышу безгә нәрсә бирә икән? Бу турыда сүз кузгаткач, кайбер танышларым миңа кызганып карап куйдылар, янәсе, картаясың, иптәш Гыйлемханов. Анысы да бардыр инде. Шулай да берсенә: «Әй син «уау» дигән сүзне заманында Тукай да кулланганын беләсеңме?» – дидем. Көлде бу миннән. Ә мин: «Тукай бу сүзне авыл этләреннән ишеткән», – дидем дә, «Су анасы» әкиятендәге мәгълүм юлларны исенә төшердем: «Вау» да, «вау» да, «һау!» да «һау» – бертуктамый этләр өрә».

Аптырады танышым, чынлап әйтәме бу, уйнапмы дигәндәй, миңа карап уйга калды. Шаяртуны аңлады, әлбәттә, тик шактый вакыт эндәшми торды. Мин дә дәшмәдем, уйлансын әле, дидем. Ә уйласаң, уелып китәрлекләр бар. Тел – һәр милләтнең иң зур байлыгы. Татар теле исә – дөнья йөзендә иң киң кулланылышта булган 14 телнең берсе. Бер яктан без шушы байлыкны саклау кирәклеге турында сөйлибез, икенче яктан үзебез үк шул байлыкны әрәм-шәрәм итәбез. Гаҗәп хәл инде бу, «уау)!»

Әле хикмәт татар телендә генә дә түгел, Россиядә рәсми рәвештә дәүләт теле булган рус теле язмышы да шактый мөшкел хәлдә. Ул да чуплànә, зәгыйфьләнә, аны куллану даирәсе тарая бара. Моңа, беренчедән, дөньяда барган милләтара ызгышлар сәбәп булса, икенче яктан үзебез дә кимен куймыйбыз.

Бу араларда телевизордан сугыш турында фильмнар күп күрсәтәләр. Безнең офицерлар телендә ике сүзнең берсе – «мать вашу». Сугыш турындагы иске фильмнарда геройлар кемнеңдер анасын телгә алып сүгенмиләр иде. Кая китте матур, әдәби сөйләм теле, «мать якасын!»

Телләрнең «сукбай» сүзләр, ягъни жаргоннар белән чуарлануы – бер хәл, әле кирәксә-кирәкмәсә чит сүзләр куллану модага керде. Әй, чит илләргә, чит телләргә кызыгабыз да инде! Бу – сукырларча ияру, ягъни «тәтәй чаба, мин дә чабам» дип яшәү галәмәте. Һәр телнең чит телләр хисабына баюы табигый, әмма без артыгын кыланабыз кебек. Чама белеп кулланмасаң, иң яхшы даруның да агуга әйләнү ихтималын онытабыз.

Россия Дәүләт Думасына чит сүзләр куллануны киметү турында закон проекты кергән иде. Белүемчә, ул беренче укылышта кабул ителгән. Закон проекты, һичшиксез, бик бәхәсле. Телне закон чыгарып кына саклап калып булмый. Безнең халыкларда милли горурлык хисләре бетеп бара төсле. Чит сүзләр кыстырып сөйләгән кеше үзен дөнья йөзендә иң акыллы, иң укымышлы һәм «продвинутый» дип хис итә, «уау!»

Әгәр дә Думада әлеге закон кабул ителсә, чит сүзләр, терминнар куллану бөтенләй тыелса, рус кардәшләребез үз телендә әйтәсе сүзен әйтеп, фикерен аңлатып бетерә алыр микән? Бу уемны бер дустыма әйткән идем, ул: «Руслар татарчага күчәр, бәлки», – дип бәхетле елмаеп куйган иде. Әмма, татарчага күчсә дә, аны шул ук язмыш көтәчәк. Чөнки татар теленә мөнәсәбәт, йомшак кына әйткәндә, әллә ни мактанырлык түгел. Аны кысу хакимияткә дә файда китерми. Телне, милләтне кысу тарихта гомер-гомергә ызгышлар тудыра килгән. Илдә-җирдә барган бүгенге вакыйгалар – әлешчә, шуңа бер мисал. Бүген өйдән чыкканда хатыныма «уау!» дидем. Ә ул миңа бик сәерсенеп карады. Алай караганы юк иде әле.

КАРАҢГЫЛЫК ТАҢ АЛДЫННАН КӨЧӘЯ – 2

Узган елның декабрендә шундый исемдә яңа елга фаразлар язуыбызга бер ел үтеп тә киткән икән инде. Үткән елгы фаразларда без төп сызык итеп: «...2022 елда, мөгаен, төп халыкара вакыйгалар Көнбатыш – Россия, Көнбатыш – Кытай ясслыгында барыр. Әгәр конфликт Көнбатыш – Кытай мәйданында көчәйсә, Россиягә Көнбатыш белән аркадашлык итәргә туры киләчәк. Учак безнең көнбатыш чикләрдә ягылса, бер дә яхшыга түгел», – дигән юлларны алганбыз.

Кызганыч, безнең фаразның икенче өлеше тормышка ашты. Һәм без 24 февральдән башлап махсус хәрби операция китереп чыгарган кыенлыклар һәм авырлыклар дулкынында яшибез. Путин хәрби хәрәкәтләрнең озак һәм дәвамлы процесс булачагын әйтте. Димәк, 2023 елда да безнең тормышка Украина белән конфликт тирән эзен салачак. Мәскәү өчен каршылыкны Россия – Көнбатыш конфликтына үстермәү бик мөһим. Кремльдә моны аңлыйлар, әмма вакыйгалар үсеше аерым кешеләр ихтыярыннан башка бара.

Ел Россия өчен шактый катлаулы шартларда тәгәлләнә. Нефтькә чик бәя билгеләү Россия чималының кыйммәтен дә, сату күләмен дә кискен түбәнәйтте. Bloomberg агентлыгы: «Бәяләр «түшәм»е гамәлгә кергән беренче атнада ук Россия нефтен экспортлау 54 процентка кимеде», – дип белдерде. Моның нәтиҗәсен без валюта курсларында күзәтәбез: соңгы тәүлекләрдә сум сизелерлек йомшарды. «Открытие» банкы җитәкчесе Задорнов долларның 75 сумлык курсын фаразлый, әмма глобаль рецессия көчәеп, «кара алтын» бәясе төшсә, 80–85 сумлык доллар да гадәти күренеш булачак, дип әйтә. Ләкин валюта курслары артык куркыныч нәрсә түгел. Халык хәзер моны тыныч кабул итә, паника юк. Матди кыенлыкларга түзеп була әле. Алар көчәячәк, әлбәттә, әмма без – матди проблемалар аша үтәргә өйрәнгән кешеләр.

Турбулентлык җәмгыять тормышының бар тармакларында да арта һәм бөтен планета буйлап җәелә, шунысы бик начар. Авырлыклар хакындагы фаразлар укыганда, укучыларда «автор аларны шатланып көтә» дигән ялгыш караш туарга мөмкин. Бу һич тә алай түгел, җилкәләргә тормыш авырлыгы өстәлүен бу юлларны язучы да теләми. Әмма тарихи үсешнең мантыйгы шундый: вакыйгалар агышы тизләнәчәк һәм торган саен катлауланачак.

2022 елның Казахстандагы канлы фетнә белән башланып китүен искә төшерик әле. Ярсыган халыкның күтәрелеп чыгуы планетаның бар почмакларына да утлы очкын кебек таралды. Хәтта хакимиятләр алдында күндәм һәм юаш булырга өйрәтелгән Кытай халкы да, пандемия чикләүләренә түзмичә, сәяси лозунглар күтәреп, компартиягә каршы шигарьләр кычкырып, бер дулап алды. Си Цзиньпинның кискен артка чигереп, вазгыятьне йомшартып калуы гына хәлне тотрыкландырды.

Иранда кайнар вакыйгалар туктамый. Аны «хатын-кыз фетнәсе» дип атап булыр иде. Ярсулы һәм канлы бәрелешләрдән соң, гыйсъянчылык хәрәкәте басыла төште, әмма баш күтәрүчеләр режимны икътисадый яктан какшату ысулын сайлый башлады. Соңгы көннәрдә алар, банклардагы бар акчаны чыгарып, системаны түнтәрергә чакырды. Бар халык банк хисапларындагы акчаны берьюлы таләп итсә, финанс системасы шунда ук эштән чыгачак, бу шиксез. Әмма андый масштаблы акцияне оештыру гына катлаулы. Төркиядә дә ислам диненә каршы көчләр «хатыннар фетнәсе» оештырырга тырышып карадылар. Бар ислам дөньясында тектоник плитәләрнең көчле хәрәкәте көтелә, әмма хәлиткеч вакыйгаларның кайчан буласын тәгәл әйтә алмыйбыз. 2023 ел чигендә үк булмаска да мөмкин. Әмма бер нәрсә бар: ислам дөньясындагы үзгәрешләр бөтен дөньяга нык тәэсир итәчәк. Россиягә аеруча.

Күз карашын, әйдәгез, үткәннәрдән киләчәккә юнәлтик. Сүзне Россия Президенты Путинга бирәбез. Октябрь ахырында ул Валдай форумындагы чыгышында дөньяны Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң иң авыр һәм куркыныч унъеллык көтүен әйтте. Сүзгә-сүз әйтсәк, «күз алдына китереп булмаслык авыр» дигән фаразны хәтерләрбез. «Мы стоим на историческом рубеже», «положение дел чревато цепью конфликтов, которые будут представлять угрозу для всего человечества» дигән сүзләр төште Россия лидеры теленнән. Бер Путин гына түгел, дөньякүләм башка лидерлар да нәкъ шундый киләчәк юрый. Бер атна элек кенә Байден яңа куркыныч пандемиянең котылгысызлыгы турында әйтте, мәсәлән. 2008 елгы кризисны тәгәл әйтеп бирүче булып даны чыккан икътисадчы Нуриэль Рубини кешелек дөньясына тирән һәм озак рецессия, ачлык, геноцидлар, эпидемияләр һәм сугышлар вәгъдә итә. Йөзләгән атаклы аналитикның һәм сәясәтче лидерларның шуңа охшаган цитаталарын китерә алыр идек.

2023 ел глобаль рецессиянең авыр сулышы белән тарихка кереп калыр, монысына без шикләнмибез. Россиядә мобилизациянең көчлерәк дулкыны башланса да, бер дә гаҗәпләнмибез. Матди кыенлыклар безне урап үтмәячәк, аларга сакчыллык һәм сабырлык белән каршы торырга туры киләчәк. Конкрет вакыйгаларның ничек барасын әйтеп булмый, билгеле, адәм баласы өчен киләчәк һәрвакытта да томанлы булып кала. Үзәк банк рәисе Эльвира Нәбиуллина күптән түгел генә: «Киләчәк хәзер беркайчан да булмаганча томанлы», – дигән иде. Цитатада мин «беркайчан да булмаганча» дигән сүзләргә игътибарны юнәлтер идем. Әйе, безгә моңарчы күрелмәгән кыенлыкларны ерып, алга барырга туры киләчәк.

Куркыныч фаразларны артка куеп, «Ни өчен шулай һәм ни эшләргә?» дигән сорауларга җавап бирергә тырышыйк. Үткән елгы фаразларда без Аллаһ илчесенең (с.г.в.): «Үзеңә файда китергән нәрсәдә тырышлык күрсәт, Аллаһтан ярдәм сора һәм беркайчан да бирешмә», – дигән сүзләрен авырлыкларны үтүнең төп кагыйдәсе итеп алырга килешкән идек. «Әле ул сүзләр безгә 2023тә дә, 2024тә дә, аннан соң да кирәк булачак», – дип тәгълләгән идек язманы. Быел шуңа вакыйгалар үсешенең төп формуласын өстибез. Ул – Аллаһның сүзләре, Коръәннән (мәгънәсе): «...Аллаһ бер кавемгә биргән нигъмәтен үзгәртмәс, хәтта ул кавем үз хәлен үзгәрткәнгә хәтле» («Рәгыд» сүрәсе, 11 аять, Ногмани тәфсире). Русча тәфсирдә ул болайрак яңгырый: «Аллах не меняет положения людей, пока они не изменят самих себя».

Бу – төп кагыйдә, аны берничек тә әйләнеп үтеп булмый. Дөнья халыклары соңгы унъеллыкларда рухи яктан бик начар хәлгә төште, әхлаксызлык һәм бозыклык яшәү рәвешенә әйләнде, оят дигән хис югалды, бар тыюлар аша җиңел генә атлап чыгылды. Катастрофаның очы шуңа барып ялгана. Кешеләр начар якка үзгәргән саен, планетада вазгыять һәлакәткә таба үзгәрә. Котылуның бер генә юлы бар: үзебезне үзебез яхшы якка үзгәртү. Гөнаһлардан тыелу, бер-беребезне изгелеккә өндәү. Без кешелек дөньясын үзгәртә алмыйбыз, билгеле, әмма үзебезне үзгәртә алабыз. Глобаль үзгәрешләр вак үзгәрешләрдән башлана. Таудан тәгәрәгән бер таш зур кантарларны үз артыннан ияртә. Шуңа күрә изгелек ташы тәгәрәтергә тырышыйк, явызлык ташы түгел.

2023 ел караңгылыгы 2022 елныкыннан куерак булыр, чөнки акрынлап таңга якынаябыз, таң алдыннан һәрвакыт караңгылык көчәя. Күптән түгел генә Россиядә Бөтендөнья рус халык җыены (Всемирный русский народный собор) булып узды. Анда Россиянең барлык конфессия вәкилләре, дөньяви хакимият лидерлары, җәмәгать эшлеклеләре катнашты. Шунда Патриарх Кирилл: «Появится некто, кто будет претендовать на глобальную власть. И с именем которого будет связан конец света», – дигән сүзләр әйтте. Бер Кирилл гына түгел, ил лидерлары белә ул «некто»ның кем икәнен. Искә төшерик әле: моннан берничә атна элек кенә, бөтендөнья күләмендә хакимлек итәргә тиешле көчкә буйсынырга чакырганы өчен, бер хатын Франция Президенты Макронның яңагына чалтыратты. «Яңа дөнья тәртибе, бөтендөнья хөкүмәте», – дигән сүзләр лидерлар авызыннан еш яңгырый. Бер генә ил дә: АКШ та, Кытай да, японнар һәм инглизләр дә суверенитетка ия түгел бүген. Безне дөньякүләм коллыкка төшерергә омтылучы көчләр торган саен активлаша. Кыска вакытка җиңүгә дә ирешерләр алар, әмма планнары барып чыкмаячак. Бу – унъеллыклар эше, Путин Валдайдагы чыгышында безгә шул хакта әйтте дә инде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

КЕМ АРБАСЫНА УТЫРСАҢ...

Чапма, тукта! Машина артыннан йөгерә, дисезме? Юк, аның көн дә артып торучы бәясен куып тота торган түгел. Илдә заводтан чыккан яңа машинаның уртача хакы 2 миллион 230 мең сумга җиткән әнә. Бу хәл Илбашы Владимир Путинны да борчуга салган хәтта. Ул машина бәяләрен «йөгәнләргә» кушкан. «Тимер ат»лар ник кыйммәтләнә? Җәяү йөрүгә калмабызмы? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга ачыклык кертергә тырышты.

Бүген машина алмаштырудан башка мәшәкатьләр дә җитәрлек, билгеле. Әмма ансыз да булмый. Хәзер тәгәрмәчсез калсаң, кулсыз-аяксыз кебек. Дөньядагы вазгыять машина базарына нык тәэсир итте. Чит ил компанияләренең илдән китүе, логистика өзелү, санкцияләр кертелү аркасында, ел азагына кадәр әлеге тармакта яңа машиналар сату күләме 70 процентка кадәр кимечәк, дип фаразлана. Быелгы тугыз айда илдә җиңел машиналар җитештерү күрсәткече 64 процентка түбән тәгәрәгән. Хәер, бер яктан кимесә, икенче яктан арткан әнә. Илдә заводтан яңа чыккан автомобильнең уртача бәясе 2 миллион 230 мең сумга җиткән. Ел башыннан бирле кайбер машиналар 70 процентка кадәр кыйммәтләнгән.

Менә шундый мода!

Әлеге вазгыять Россия Президенты Владимир Путинның да борчуга салган. Узган атнадагы утырышларның берсендә ул автомобильләргә бәя артуны карап тикшерергә кушты. «Илдә яшәүче гаиләләрнең машина сатып алу мөмкинлеге булырга тиеш», – диде Илбашы. Киләсе елда автомбиль бәяләренең күп дигәндә 12 процентка артачагын әйтте. Ярар, анысын вакыт күрсәтер. Чынбарлыкка әйләнеп кайтыйк. Баксаң, «тимер ат»ларга бәяләр быел мартта кискен югары сикергән. Автомобильләр уртача 45 процентка кыйммәтләнгән. Җәй дәвамында бераз туктап торган бәяләр көз көне кабат югары үрмәли башлаган. Моны базарда автомобильләргә кытлык булуга бәйләп аңлатканнар. Читтән кайтмагач, үзебезнеке генә җитми, янәсе.

Тик соңгысы белән түрәләр килешми. «Ил базарында яңа автомобильләргә кытлык юк. Сатып алырга машина калмый, дигән хәбәрне махсус, бәяләрне арттыру өчен генә тараталар», – диелгән илнең Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы хәбәрендә. Әйтүләренә караганда, базардагы вазгыятьне чит ил машиналары хисабына да, үзебезнекеләрне җитештерү бәрабәренә дә, даими рәвештә контрольдә торалар.

– Бүген нәкъ менә үзең теләгән машинаны сатып алу кыенлашты, – ди автомобильләрне сату-алу белән шөгыльләнүче Азат Хәснетдинов. – Минемчә, автомобиль базарындагы бәяләргә, беренче чиратта, әнә шул тәэсир итә. Яңа машина бәясе кыйммәт. Ә тотылган машиналар базарында берәүләр ошап бетмәгән автомобиль өчен кесәсендәге акчасын чыгарып бирергә ашыкмаса, икенчеләр сатуда аз калган «иномарка»ларны кыйммәтрәк бәядән озатмакчы. Соңгы ярты елда Кытайда җитештерелгән машиналарга ихтыяҗ артты. Кытайлылар халыкны төрлечә кызыктыра. Бу көннәрдә генә яңа «Омода» («о» теркәгече һәм «мода» сүзләреннән. – **Ред.**) машинасы сатуга чыкты. Бәясе 2 миллион сумнан башланган «тимер ат»ка карап: «О, машина!» – диясе генә кала.

Эшкуар сүзләрен белгечләр дә куәтли. «Автостат» мәгълүматларына караганда, узган атнада илдә иң күбе Кытай автомобильләре сатылган. Россиялеләр әлеге илдән кайтарылган 3 мең 742 машина сатып алган. Бу – барлык сатылган автомобильләрнең 35 проценты, ди белгечләр.

«Мерседес» тузан җыя

Үзебезнең «тимер ат»ларга килгәндә, илдә яшәүчеләр барыннан да бигрәк «Лада Гранта»ны сайлый. Быел гыйнвар – сентябрьдә 52 мең 117 данә шундый машина сатылган. Икенче урында – «Лада Веста» (29 мең 93 данә). Беренче өчлеккә «Лада Ларгус» та (11 мең 211 данә) эләккән.

– Без күбрәк «Лада» машиналарын сатабыз, – ди башкаладагы автомобиль салоннарының берсендә эшләүче Айгөл Мостафина. – Үзебездә чыккан машиналарны, нигездә, районнарда яшәүчеләр сатып ала. Авылдан килүчеләр арасында кредит рәсмиләштерүчеләр аз. Акчалары – кулларында. Кредит рәсмиләштерергә үгетләргә дә туры килә кайчак. Чөнки безгә автомобильне дәүләт программасы буенча кредитка сату отышлырак. Чит ил машиналарына килгәндә, Кытайныкылар беренче урында тора. Бигрәк тә «Хавал», «Джили»га сорау зур. Салонда чит ил машиналары күп калмады инде. «Киа», «Хюндай» ише халык арасында популяр булган автомобильләр бетеп бара.

Сатучы сүзләренә караганда, иске машина сорап мөрәҗәгать итүчеләр күбрәк.

– Бездә кулдагысын трейд-инга тапшыру да каралган бит. Аз булса да ярдәм. Узган ел белән чагыштырганда, машина бәяләре бик нык артты. Ә кыйммәтле чит ил машиналары сатып алучылар бермәбер кимеде. Мәсәлән, соңгы ике атнада нибары бер «Тойота» саттык. Анысын да кулдагы акчага сатып алдылар. «Мерседес»лар шул килеш тора. Яңа ел алдыннан базарда җанлану күзәтелә. Әйткәнемчә, күбрәк иске машина сатып алалар. «Лада» автомобильләрен сатарга дәүләттән бирелүче ташламалы автокредит программасы ярдәм итә. Сатарга дигән машиналар җитәрлек. Автомобиль базарында ун елга якын эшләүче кеше буларак шуны әйтә алам: биш-алты елдан барыбыз да Кытай машиналарына күчеп утырачакбыз. Россия автомобиль базары искерә, ә чит ил җитештерүчеләре арасында Кытайдан да тырыш халык юк, – ди Айгөл Мостафина.

АЛДАГЫ БЕР ЕЛДА МАШИНА САТЫП АЛЫРГА ҖЫЕНАСЫЗМЫ?



- Бу хакта уйлаганым да юк 42,9%
- Аласым килә, тик мөмкинлегем юк 27,2%
- Әле күптән түгел генә машина сатып алдым 17,2%
- Аласым килә, әлегә уйлыйм 5,4%
- Хәзер машина бик кыйммәткә төшә, сатарга җыенам 5,1%
- Әйе, яңа машина эзли башладым инде 2,2%

«Автостат» аналитика агентлыгыннан

rg.ru

2022 елда Россиядә популяр булган автомобильләргә бәяләр ничек үзгәргән?

Машина моделе	Кыйммәтләнү (%)	Гыйнвар (мең сум)	Август (мең сум)
LADA Granta	+13,3	598,9	678,3
LADA Vesta	+30	862,9	1 121,9
Kia Rio	+41,4	1 014,9	1 434,9
Hyundai Solaris	+45,2	970,0	1 408,0
Hyundai Creta	+43,1	1 299,0	1 859,0
Renault Duster	+41,1	1 147,0	1 618,0
LADA Largus	+56,8	829,0	1 300,9
Volkswagen Polo	+51,6	1 068,9	1 620,9
LADA Niva Travel	+21,3	879,9	1 066,9
Toyota RAV4	+23,1	2 169,0	2 671,0

Исегезгә төшерәбез: быел июль аеннан башлап ташламалы автокредитны гаиләдә 18 яше тулмаган кимендә бер бала тәрбияләүчеләр, табиблар, укытучылар һәм беренче тапкыр машина сатып алучылар рәсмиләштерә ала. Мондый мөмкинлек алты «яшь»тән өлкәнрәк автомобильне трейд-инга тапшыручыларга да бирелә. Дөрес, кимендә бер елдан артык бу машинага хуҗа булып торырга кирәк. Автокредитны хәрбиләргә һәм мобилизациягә китүчеләрнең гаиләләренә бирә башларга да тәкъдим иттеләр. Дәүләт машинаның 20 проценты күләмендә ташлама бирә. Федераль программада үзебездә җитештерелгән «тимер ат»лар һәм 2 миллион сумга кадәр «Хавал Джолион» катнаша.

Эче дә, тышы да кыйммәт

Түбән Камада яшәүче Ленар Сабитов ике ай элек кенә яңа машиналы булган.

– Иске «Киа»ны сатып, 1 миллион 500 мең сумга яңа «Веста Кросс» сатып алдым. Тегесе бик нык искергән иде. Шуңа күрә автомобильне алмаштырырга кирәк дигән карарга килдем. Кыйммәт, әлбәттә. Кредит рәсмиләштерергә туры килде. Чит ил машиналарына кызыкмадым да. Иртәгә нәрсә буласы билгесез. Киләчәктә «иномарка»ларга запас частьлар табып булмаячак, диләр бит, – ди ул.

Казанда автомобильләр ремонтлау белән шөгыльләнүче Рөстәм Хәкимов сүзләренә караганда, «тимер ат»ларга запас частьлар кайтаруда кыенлыклар юк. Дөрес, аларның бәяләре бермә-бер кыйммәтләнгән.

– Без күбрәк Мәскәү, Түбән Новгородтагы арадашчылар белән эшлибез. Гарәп Әмирлекләреннән кадәр кайтарылучы запас частьлар да бар. Соңгы арада Германиядә чыккан машиналарны ремонтлау бераз кыенлашты, чөнки запас частьлары юк. Ә болай бернинди кытлык та сизелми. Кытайның эшли белмәгәне юк әле, бер дә булмаса, шул базарга күчәрбез. Бәяләр генә артты. Мәсәлән, ел башында автомобиль шәме 1 мең сум торса, хәзер ул – 3 мең сум. Запас частьлар, нигездә, 50–100 процентка кыйммәтләнде. Машина булгач, төзәтәсең инде. Беркемнең дә җәяү йөрисе килми, – ди Рөстәм.

Быел гыйнвар – ноябрь айларында илгә 221 меңнән артык «иномарка» кайткан. Узган ел белән чагыштырганда, бу икеләтә диярлек күбрәк. Мондый күренеш киләсе елда да дәвам итәчәк, дип фаразлана. «АвтоВАЗ» исә 2023 елда 400 мең машина эшләп чыгарырга ниятли. Җиңел машина базарының 40 проценты «Лада» машиналарына туры килергә мөмкин, диләр. Чагыштыру өчен: бу ел азагына кадәр «АвтоВАЗ»да 220 мең машина җитештерәчәкләр. Ул арада Мәскәү заводында яңа «Москвич» машинасын күпләп сата башларга җыенуларын да әйткәннәр. Менә сиңа замана!

Эльвира ВӘЛИЕВА

Фикер

Юрий КУЛАГИН, «Бөтенроссия автомобильчеләр җәмгыяте»нең Татарстан төбәк бүлеге рәисе:

– Автомобиль базарына машиналарга кытлык, бәяләр арту һәм халыкның сатып алу мөмкинлеге киму бик нык тәэсир итте. Хәзер очсызрак «тимер ат»ларга ихтыяҗ күбрәк. Ник дисәң, яңа машина бәяләре янына якын да килә торган түгел. Шуңа күрә халык ничарадан бичара дигәндәй, үзебездә чыккан машиналарга өстенлек бирә. Хәзер Кытай автомобильләрен сатып алучылар да шактый. Яңа машина алырга мөмкинлеге булмаганнар исә икенчел базарга бара. Безнең илдән киткән автомобиль брендлары да нигездә шунда хәзер. Элек 700 мең сумга яхшы машина сатып алып булса, бүген 1 миллион сумга да берни табып булмый. Вазгыять киләсе елда да үзгәрмәячәк. Тагын да начаррак булмаса әле. Керемнәр шул ук, ә машина бәяләре артканнан-арта. Шуңа күрә халыкның машина сатып алу мөмкинлеге кимеячәк. Җәяү йөрмәсәк тә, җәмәгать транспортына күчеп утырырга туры килмәгәе.

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ҮЗЕБЕЗДӘ ТУМАГАЧ...

РАЙОННАРДАГЫ БАЛА ТУДЫРУ ЙОРТЛАРЫ НИК ЯБЫЛА?

Безнең үзебездә бала тудыру йорты булырга тиеш! Спас районы халкы шулай дип көрсенә. Хәзер монда хатын-кызлар Базарлы Матакка яки Чистайга барып бала таба. Республика күләмендә мондый язмышка дучар булган бала табу йортлары шактый. Белгечләр, районнардагы бүлекләр ябылуның уңай яклары күбрәк, дип ышандырырга тырыша. Алар белән килешмәүчеләр дә шактый.

Алинә Тажетдинованың шәхси архивыннан

Юл газабы өстәлә

Спас районының Танкеевка авылында яшәүче Кристина Малыгина быел җәй әни булган. Тулгагы башлангач, ашыгыч ярдәм дә чакырмаган, иренең өйгә кайтуын да көтеп тормаган, машинаны кабызган да бала тудыру йортына киткән. «Озак уйлап тормадым, Базарлы Матак хастаханәсенә рульдә үзем килдем. Биредә мине бала таптыручы шәфкать туташлары каршы алды. Озак көтәргә туры килмәде: сәгать ярым да үтмәде, сабыем туды», – ди яшь әни.

Бәхеткә, бар да яхшы тәмамланган. Бала табу йортына барып җитәргә өлгерә алмаган булса, бу хәлләрнең нәрсә булып беткәнен күз алдына китерү дә кыен. Үзең яшәгән җирлектә бала тудыру йорты булмау, беренче чиратта, әнә шул ягы белән куркыныч та инде.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, Спас бала тудыру йорты монда бала табучылар саны елдан-ел кимү аркасында ябылган. Соңгы елларда Мөслим, Апас, Югары Ослан, Балык Бистәсе, Кайбыч, Кама Тамагы, Яңа Чишмә, Чирмешән, Мамадыш районнарындагы бала тудыру бүлекләре дә ябылды. Елына 150дән кимрәк бала туган районнар бу. Дөрес, дөнья булгач, төрле хәлләр була. Шуңа күрә ябылган дип саналган әлеге бала табу йортларында бүген ургент заллар эшләп килә. Тулгагы башланган хатын-кызны тегендә-монда алып барып җиткерү өчен вакыт бик аз калган очракта, аны шушында гына бала таптыралар. Биредә барлык шартлар да тудырылган. Кирәкле белгечләр дә эшли. Бүген республика районнарында барлыгы 36 бала тудыру йорты исәпләнә.

Аз тапсалар, файда юк

Татарстан сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков сүзләренә караганда, бала тудыру йортын ябу-ябмау мәсьәләсе хәл ителгәндә, иң элек анда елына күпме бала тууга игътибар итәләр.

– Елына якынча 80ләп бала тудыру очрагы гына теркәлә икән, бу инде дөрес түгел. Монда акушер-гинекологның һөнәри осталыгы да, квалификация мәсьәләсе дә зур роль уйный. Аннары хәзер бөтен ил күләмендә кечкенә җирлекләрдәге бала тудыру йортларын ябу күзәтелә. Эш күләме җитәрлек дәрәҗәдә булмауга да игътибар итәләр. Кызганыч, андый бала тудыру йортларында аналар арасында үлем-китем очраклары да күзәтелә. Кайбер төбәкләрдә мондый бала тудыру йортлары ябылды инде. Аларга икенче дәрәҗәдәге, ягъни районара бала тудыру йортлары алмашка килде, – ди министр. – Авыр хәлләр тумасын өчен, хатын-кызлар консультациясе бөтенләй башка дәрәҗәдә төзелергә тиеш. Катлаулы очракларга, өзлегүләргә юлыккан хатын-кызлар иң югары яки өченче дәрәҗәдәге бала тудыру йортларында дәваланырга тиеш.

Шуны истә тотып, бүген район бала тудыру йортларында сау-сәламәт, баланы үзе табарга сәләтле хатын-кызлар гына әни була. Әгәр аның сәламәтлегендә берәр кимчелек, авыруы бар икән, булачак әнине Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Лениногорск, Чистай, Яшел Үзәндә урнашкан эрерәк бала тудыру йортларына озаталар. Югары хәвеф төркеменә керүче авырлы хатын-кызлар исә фәкать Республика клиник хастаханәсендәге перинаталь үзәктә генә табарга тиеш.

Йорттан ерак булмасын

Республикада йозак эленгән бала табу йортларының соңгысы – Мамадыш районында. Тумышы белән шушы районнан булган язучы, журналист Нәзифә Кәримова моны халык саны 40 меңнән арткан Мамадыш өчен гаҗәп хәл дип саный. Анда яшәүче туганына да баласын Чаллыга барып табарга туры килгән.

– Бала табу урыннары яшәгән җиргә якын булырга тиеш. Бу оптимизация дигән нәрсә белән бала табу йортларын, хастаханәләрне ябу җинаяткә тиң. Элегрәк алар хәтта зур авылларда да бар иде. Районнарда перинаталь үзәкләр үк ачмаслар инде. Әмма телевизордан күрсәтеп торалар: ил буенча күпме авыру балага дәваланырга акча җыялар. Аларның күбесе туганда алган чирләр аркасында шундый авыру бит. Уңайлыклар булмагач, каян тусын ул сау-сәламәт бала. Менә шул турыда уйласыннар иде, – ди ул.

Мәсьәләгә ачыклык кертергә теләп, Мамадыш район хастаханәсенең баш табибы Дамир Хаҗиев белән элемтәгә кердек. Баш табиб сүзләренә караганда, биредәге бала табу бүлеге дә ике ел элек – бала табучылар саны елдан-ел кимү аркасында ябылган.

– 2010 нчы елларда районда 500дән артык бала туа иде. Акрынлап кимеп, хәзер 100–120гә калды. Бездә быел, мәсәлән, 91 бала туды. Шуның берсен үзебездә таптырдык. Гадәттән тыш очракта баланы шулай үзебездә таптырабыз. Моның өчен ургент зал бар, анда барлык шартлар да тудырылган. Өч акушер-гинеколог, неонатолог, реаниматологыбыз да һәрчак әзер тора. Табиблар җитәрлек. Бала һәм әнисенең хәле тәртиптә булса, алар бездә кала, өч-дүрт көннән чыгарабыз. Катлаулырак очракларда үзебездә туган баланы шундук башкаладагы перинаталь үзәккә озатабыз. Бүген бездә барлыгы 137 хатын-кыз учетта тора, – ди ул.

Җидесе – үзебездә

Мөслим районында да бүген, бала табу йорты ябылса да, ургент зал эшләп килә. Баш табиб Дамир Сөләйманов сүзләренә караганда, ел башыннан бирле биредә 7 бала дөньяга аваз салган. Кайбыч районында ел башыннан бирле дөньяга килгән 70 баланың берсен үзләрендә таптырганнар. Баш табиб Гөлнара Сафиуллина фикеренчә, районнарда бала табу бүлекләре күпләп ябылуга аптырыйсы юк.

– Соңгы арада безнең елга 50–60 бала табу очрагы теркәлә иде. Моның өчен генә тулы бер смена тотудан файда юк. Бала тудыру йорты шуңа ябылды. Бу белгечләрнең үзләре өчен дә начар. Гел эшләп, белем-күнекмәләреңне гамәлдә кулланып тормагач, начар бит. Аннары перинаталь үзәкләрдә, шәһәрдәге бала табу йортларында шартлар бөтенләй башка. Җиһазлары да яңа. Белгечләр дә югарырак квалификацияле. Сайлау мөмкинлеге булса, үзем дә шунда бала табу ягын карар идем, – ди белгеч.

Кайбычтагы булачак әниләр исә бүген Яшел Үзәндә бала таба икән. Катлаулырак очракта аларны башкаладагы 7 нче номерлы шәһәр хастаханәсе каршындагы 1 нче бала табу йортына яки Республика клиник хастаханәсендәге перинаталь үзәккә озаталар.

Белгече дә кирәк

Балтач район хастаханәсенең бала тудыру бүлегенә ябылу куркынычы янамый. Ник дигәндә, биредә туучылар саны элек-электән югары. Хастаханәнең баш табибы Газинур Дәүлиев биредәге бала тудыру йортын яшәткән икенче бер шартны да атый:

– Бездә бик көчле кадрлар эшли. Районда искитмәле, заманча бала тудыру йорты төзелеп тә, анда тәҗрибәле белгечләр булмаса, аннан мәгънә юк. Бездә хәзер ике акушер-гинеколог, неонатолог, педиатрлар бар. Авыр очракларда хатын-кызны Казанга озатабыз. Безнең үзебезгә Арчаның Балтачка якын авылларыннан, Сабадан килеп бала табучылар да шактый. Казаннан әти-әнисе янына кунакка кайткан җирдән биредә бала табучылар да була. Тормыш булгач, төрле чак була бит, – ди баш табиб.

Газинур Дәүлиев сүзләренә караганда, демографик күрсәткечләрнең кимү җиле Балтачны да читләп үтмәгән. Соңгы елларда биредә туган балалар саны шактый кимегән. Чагыштыру өчен: элегрәк Балтачта елына 360–380 бала туган булса, быел 300гә тулырмы икән, дип торалар.

Бәхет эше

Яшерен-батырын түгел, районда туучылар саны кимүгә халык телендә йөргән имеш-мимешләр дә зур йогынты ясый. Районда бала таптыра белмиләр, шуңа шәһәргә барып табу ягын карарга кирәк, дигән фикер яши халыкта. Бу сүзләрдә ни дәрәҗәдә хаклык бар? Бу сорауны үзебез элемтәгә кергән белгечләргә дә бирдек.

Балтач район үзәк хастаханәсе баш табибы Газинур Дәүлиев фикеренчә, бөтен кешене дә бер калыпка салырга ярамый. «Шәһәрдә көненә унар бала таптырган белгечнең квалификациясе икенчерәк була, билгеле. Әмма районда да баланы начар таптыралар димәс идем. Бу инде – бәхет эше. Кеше факторы да зур роль уйный», – ди ул.

Аның бу фикерен Мамадыш район хастаханәсе баш табибы Дамир Хаҗиев та куәтләде.

> Күбрәк бала таптырган, күбрәк операция ясаган саен, табибларның тәҗрибәсе зуррак була. Аннары район хастаханәсендә бер үк белгеч көндез дә эшли, төнлә дә килергә тиеш. Көн-төн, кайчак атналар буе хастаханәдән чыга алмыйлар. Шәһәр җирендә исә көндез бер бригада эшли, төнлә икенче бригадасы килә алмашка. Аларның бөтен шартлары бар. Ул шулай булырга тиеш тә. Бүген район җирендә андый белгечләргә эшләргә бик авыр. Аларның көне дә, төне дә юк. Больничный да алып булмый. Отпускыга китә башласаң да, як-ягыңа каранасың, – ди баш табиб.

Сүз уңаеннан, киләсе елда Казанда 7 нче шәһәр хастаханәсе каршында яңа перинаталь үзәк төзеләчәк. Моннан тыш Казанның Гаврилов урамында һәм Дәрвишләр бистәсендә 480 урынлы яңа балалар хастаханәләре дә барлыкка киләчәк.

Фикер

Чулпан НИГЪМӘТҖАНОВА-ГАРӘФИЕВА, психология фәннәре магистры, психолог:

– Йөкле чакта хатын-кызның психологиясе 180 градуска үзгәрә. Гормоннар уйнау галәмәте бу. Әни булырга әзерләнгән хатын-кыз күп нәрсәгә борчыла, шикләнеп карый. Хатын-кыз үзенә һәм баласына берни дә янамавына инанырга, моны төгәл белергә тиеш. Кул сузымында гына бала тудыру йорты булмау аның бу халәтен тагын да катлауландырырга, кирәксә-кирәкмәсә борчылуына да сәбәп булырга мөмкин. Яшәгән җирлектә тиешле шартлар булу хатын-кызның бала алып кайту-кайтмау карарына да күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясый ала.

БОЗ КАПКЫНЫНДА

Ноябрь ахырында яуган бозлы яңгырлар республиканың Идел аръягы районнарын боз капкынында калдырды. Чүпрәле, Тәтеш һәм Буа районнарында электр чыбыкларының бозлануы нәтиҗәсендә 86 торак пункт көтмәгәндә утсыз калды. Аларда 10336 кешенең яшәвен исәпкә алсак, гадәттән тыш хәлнең масштабларын аңлатып торырга кирәкмидер. Боз 400дән артык электр баганасын ега. Авылларның бер өлеше тиз арада дизель генераторларына, калганнары бөҗра схемасы буенча тоташтырыла. «Сетевая компания» хезмәткәрләренә бу көннәрдә табигый каза белән гадәттән тыш авыр шартларда көрәшергә туры килде.

Мондый хәлне күргәнебез юк иде...

– Барысы да 22сеннән 23 ноябрьгә каршы төндә башланды, – ди Чүпрәле районы электр челтәрләре җитәкчесе Айрат Низамов. – Җепшек кар яңгыр белән кушылып, электр чыбыкларына ябышып, боз хасил итте.

Беренчеләрдән булып, районда иң күп халык яшәгән Кече һәм Зур Чынлы авыллары утсыз кала.

– Зур Чынлы белән Кече Чынлы авыллары арасы җиде чакрым – дип сөйли әлеге вакыйгаларның шаһиты фермер Равил Бикчуров. – Шул арада егермедән артык электр баганасы ауган иде. Миңа 63 яшь. Шушы гомеремдә электр белән бәйле мондый бәла-казаны күргәнем булмады. Иртәдән алып кичке сәгать сигезләргә кадәр утсыз торырга туры килде. Энергетикларга зур рәхмәт. Егетләр таңнан алып төнгә кадәр бертуктаусыз эшләде, халыкны тизрәк утлы итәр өчен бик тырыштылар.

Күз алдына китерегез: ике багана арасындагы электр чыбыкларына бер тоннага якын боз «кунаклый». Бу авырлыкны күтәрә алмыйча, электр чыбыклары сыгылып төшә, кайсы шартлап өзелә, баганалар ава. Берничә көннән һава торышы үзгәреп китеп, әлеге хәлләр тагын кабатлана. Өченче көннәргә бозлы кар белән капланган агачлар да, авырлыкны күтәреп тора алмыйча, бөгелеп яки сынып төшә башлый. Бу агачлар якындагы электр чыбыкларын өзә. Ул көннәрдә гомумән алганда 255 чакрым озынлыктагы 6–10 кВт егәрлегендәге һава линияләренә зыян килә. 283 багана ава, 37 авыл утсыз кала.

– Күршеләребез Тәтеш, Буа белән чагыштырганда, безнең райондагы электр чыбыклары тулысы белән боз капкынында калды. Калын боз белән капланмаган бер генә урын да юк иде. Мәхшәр булды ул, – ди районның электр челтәрләре баш инженеры Радик Сафин. – Баштагы минутларда билгесезлек биләп алды, ләкин ул халәт бик тиз узды. Беренче сәгатьләрдә үк безгә ярдәмгә күрше Апас, Тәтеш, Буа филиалларыннан бригадалар килә башлады. Аларга башкалар кушылды. Алабуга электр челтәрләре генә 18 бригада җибәрде. Подрядчыларыбызга рәхмәт. «Средневолжсксельэлектросетьстрой», «Татэнергострой», «Электронефтегаз», «Опора плюс» оешмаларының бригадалары, тиз арада авария урыннарына килеп җитеп, шунда ук эшкә кереште.

«Сетевая компания» җәмгыятенең генераль директор урынбасары Азат Мәҗитов, бу авариядә иң зур авырлык – билгесезлек иде, ди.

– Беренче көннәрдә вазгыятьнең ни дәрәҗәдә катлаулы булуын чамалау авыр булды. Һәр 2–3 сәгать саен саннар үзгәреп торды. Шуңа да без, ресурслар җитәрме икән, дип борчылдык. Беренче тәүлектә эшләүчеләр өйләренә кайтып китте. Аларны яңа бригадалар алыштырды. Икенче көнне вазгыять катлауланып, ауган баганалар саны 300гә җиткәч, без егетләрне өйләренә кайтарып җибәрмәскә кирәклеген аңладык, – дип сөйли ул.

Бозлы яңгыр зур кыенлыклар тудырса да, һөнәри осталыкны эшкә җигеп, энергетиклар сынатмый. Аларга ауган баганаларны алыштырырга, электр чыбыкларын боздан арындырырга, өзелгәннәрен ялгарга, җирдә ятканнарын күтәрергә туры килә. Без барган көннәрдә дә егетләр чыбыкларны боздан чистарту, өзелгәннәрен ялгау белән мәшгуль иде.

– Бозны агач таяклар белән бәреп төшерәбез. Кайдадыр боз җайлырак төшә, кайдадыр тырышырга туры килә. Каты бәрергә ярамый – электр чыбыклары өзелергә мөмкин, – дип аңлаттылар безгә.

– Ул көннәрдә безнең иң беренче максатыбыз халыкны тиз арада утлы итү иде, – ди Радик Сафин. – Авылларның бер өлешен ауган баганалы линиядән аерып, резерв линиясенә тоташтырдык. Андый мөмкинлек булмаган торак пунктларга дизель генераторлары куйдык. Шуңа күрә, иң күп дигәндә дә, кешеләр 15 сәгатьтән артык утсыз утырмады.

Авария булган участокларны төзекләндерүдә энергетикларны материаллар белән тәэмин итүче оешма да зур көч куя. Баганалар, чыбыклар төягән машиналар гадәттән тыш хәл урыннарына шул ук төндә кузгала.

– Төнлә миңа Буа электр челтәрләренең баш инженеры шалтыратып, тиз арада хәлне аңлатты, – дип искә ала «Стройинвест» компаниясенең башкаручы директоры Радик Гатауллин. – Буадагы складта – 22, Столбищеда 78 багана бар иде. Аларны шунда ук төяп озаттык. Ләкин бу гына җитмәде. Беренче-икенче көннәрдә ауган баганаларның саны сәгать саен артып торды. Шуңа да үзебезнең складлар бушагач, турыдан-туры Түбән Камадагы баганалар ясый торган заводка шалтыраттык. Алар тиз арада, хәлне аңлап, ярдәм итте.

«Сетевая компания» җәмгыятенең генераль директоры Илшат ФӘРДИЕВ:

Чын белгечләрнең осталыгы менә шундый кырыс шартларда сынала. Авыр вакытларда төшенкелеккә бирелмәскә кирәк. Безнең алда бер генә бурыч торды: кыска вакыт эчендә районнарны һәм шәһәрләрне утлы итү. Буа электр челтәрләре хезмәткәрләре белән бергә компаниянең башка филиаллары да бозлы яңгыр китергән зыянга каршы көрәште. Чүпрәле районы җитәкчелеге зур ярдәм күрсәтте. Подрядчы оешмаларның коллективларына да рәхмәт сүзләре җиткерәсе килә. Бәла-каза электр чыбыкларын бозга катырырга, баганаларны егарга сәләтле, тик үз эшен бөтен җаны-тәне белән яратып башкарган кешеләрнең осталыгын берни дә җиңә алмый.
22 декабрь – энергетика тармагында эшләүчеләрнең һөнәри бәйрәме. Энергетикларның хезмәте чыннан да тынгысыз. Аларның бик азы гына бу бәйрәмне гаиләләре янәшәсендә каршы ала. Кулланучыларны тәүлек буе өзлексез электр энергиясе белән тәэмин итәр өчен, алныялны белми эшләргә кирәк. Мин аларны бәйрәмебез белән чын күңелдән тәбрик итәм. Бәхет, сәламәтлек, гаиләләренә иминлек телим. Теләкнең иң зурысы: бәла-казасыз, фаҗигаләрсез генә эшләргә язсын.

«Өч көн йокламадык»

«Сынауларны ерып чыгып, авыр чакта ярдәмгә килә торган тырыш хезмәттәшләребез барлыгына кабаттан инандык». Ул көннәрдә Айрат Низамов әнә шундый нәтиҗә ясаган.

– «Сетевая компания» үзенең никадәр көчле, бердәм булуын тагын бер кат раслады, – ди ул. – Һәр бригада бер төн эчендә 18 багана утыртты. Беркем дә зарланмады. Хезмәттәшләрне ашатырга, эчертергә, яшәү урыннарын булдырырга кирәк иде. Бу яктан район администрациясенә аерым рәхмәт.

Хәер, ул көннәрдә йокы, ашау кайгысы булмады, ди Чүпрәле районы электр челтәрләре мастеры Илмир Миначев. Ул үзе шәхсән өч тәүлек йокламыйча, аны аяк өстендә уздырган. Беренче төндә иртәнге өчкә кадәр баганалар утыртып, чыбыкларны төзәтеп чыкканнар. Икенче төндә башка участокларга күчкәннәр.

Евгений Михайлов хезмәттәшләренә ярдәмгә Зәйдән килгән. 2008 елда – Актанышта, 2010 елда Тукай һәм Зәй районнарында охшаш хәл күзәтелгән.

– Тик биредә масштаблар бөтенләй башка, зуррак. Соңгы көннәрдә салкынайтты. Салкынга кешеләр түзә, ә менә техника чыдамый, – ди ул.

Чыдамлылык үрнәге

«Сетевая компания»нең Буа электр челтәрләре филиалы директоры Айрат Сәмигуллин бу яклар өчен бозлы яңгырларның бик сирәк күренеш булуын әйтте.

– Эшләр табигать шартлары белән катлауланды, баганалар берничә көн дәвамында сынды һәм ауды. Белгечләр аларны төзәтеп, утны ялгап кына җибәрә, иртән шушы ук линияләрдә тагын авария килеп чыга, – ди ул.

Авариянең беренче көннәрендә үк ачык кырда эшләгән «Опора Плюс» җәмгыяте директоры Евгений Баландин әйтүенчә, Чүпрәле – кара һәм йомшак туфраклы район. Җир дә ныклап туңмаган. Шуңа күрә беренче көннәрдә куелган баганалар кабат авып, электр чыбыкларын өзеп җәфалаган.

– Бары тик икенче көнгә генә линияләрнең ныклыгы артты. Ул көннәрдә барлыгы 436 багана алыштырдык. Бозлы яңгыр китергән зыянны ерып чыгар өчен күп көч кирәк булды. Кешеләр берничә көн йокламыйча, үзләренең никадәр тырыш, чыдам, оста һәм ышанычлы булуларын күрсәтте, – ди ул.

«Сетевая компания»нең матбугат хезмәте

Зөһрә САДЫЙКОВА

26 декабрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
10.00, 23.00 «КОГДА ПАПА ДЕД МОРОЗ» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе « 6+
12.00, 22.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ» (татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә « 6+
19.00, 00.20 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «АЛМАШ». Телевизион сериал премьерасы 12+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Каравай». Искусство войлока 6+
00.45 «Ватандашлар « 12+
01.10 «Кәмит Җәвит» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». Телесериал премьерасы 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.50, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
00.40 «Татарлар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское /Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «КАЗАНОВА В РОССИИ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Елена Яковлева, Сергей Перегудов, Александр Балуев, Ирина Таранник, Александр Дзюба. «ДАМА С СОБАЧКОЙ» 12+
23.15 «Вечер» 12+
02.00 Анна Тараторкина, Александр Пашков, Андрей Биланов. «ЧАСТНЫЙ ДЕТЕКТИВ ТАТЬЯНА ИВАНОВА. ДОРОГАЯ МОЯ СЛУЖАНКА» 12+
03.50 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Профессиональный бокс. Айк Шахназарян против Исмаила Галиатано. Трансляция из Москвы 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 15.50, 22.30 Новости
07.05, 21.45, 00.25 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00, 00.05 Спецрепортаж 12+
10.25, 01.05 Бокс. Bare Knuckle FC. Майк Вертрила против Луиса Пауло Терра. Трансляция из Таиланда 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «География спорта. Вершина Теи» 12+
13.50, 04.35 «Футбол на все времена» 12+
14.25 Спортивный дайджест 0+
15.55 «Громко» Прямой эфир
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Металлург» (Магнитогорск) – «Трактор» (Челябинск). Прямая трансляция
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
22.35 Бильярд. «BetBoom Лига Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
02.10 Новости 0+
02.15 «Конор Макгрегор. Печально известный». Документальный фильм 16+
04.05 Матч! Парад 16+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.45 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Владимир Ильин, Дмитрий Миллер. «АГЕНТСТВО «СПРАВЕДЛИВОСТЬ» (S) 16+
22.00, 00.05 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
02.20 Остросюжетный детектив «ЯРОСТЬ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «В огне» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «ВЕНЕЦ ТВОРЕНИЯ» 16+
19.00 «ВСПОМИНАЯ ТЕБЯ» 16+
23.00 «Порча». «Камень утраты». «Голоса» 16+
00.05 «Знахарка» 16+
00.35 «Верну любимого» 16+
01.05 «Понять. Простить» 16+
01.55 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.45 «Тест на отцовство» 16+
04.25 «Давай разведёмся!» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

04.45 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. УДАРНАЯ ВОЛНА». 3-я и 4-я серия 16+
06.30 «26 декабря – День войсковой ПВО». Документальный фильм. Премьера! 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 00.50 «БОЛЬШАЯ ПЕРЕМЕНА». 1-я серия 12+
10.40, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05, 02.55 «КАМЕНСКАЯ». «СТЕЧЕНИЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВ» 16+
15.00 Военные новости. 16+
15.40 «КАМЕНСКАЯ». «ИГРА НА ЧУЖОМ ПОЛЕ» 16+
18.50 «Морская авиация. Ударная сила океанов». Документальный сериал. Фильм 1-й. Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Кто придумал СССР» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «БАРМЕН ИЗ «ЗОЛОТОГО ЯКОРЯ» 12+
01.55 «Гагарин». Документальный фильм 12+
02.25 «Выбор Филби». Документальный фильм 12+

27 декабрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
10.00, 23.00 «КОГДА ПАПА ДЕД МОРОЗ» 12+
11.00 «Азбука долголетия « 6+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ» (татар телендә) 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Казанское суворовское. Школа патриотов». Телефильм 12+
18.00 «Казаннан – Казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «АЛМАШ». Телевизион сериал премьерасы 12+
21.00 «Черное озеро» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Роальд Сагдеев. О времени и о себе 12+
00.40 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
01.10 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар» 6+
15.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Венера Шәрипова турында телеочерк 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
18.50, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское /Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «КАЗАНОВА В РОССИИ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45, 03.05 Информационный канал 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Елена Яковлева, Сергей Перегудов. «ДАМА С СОБАЧКОЙ» 12+
23.15 «Вечер» 12+
02.00 Анна Тараторкина, Александр Пашков, Андрей Биланов, Виктория Полторак, Татьяна Лянник, Максим Емельянов, Марина Яковлева. «ЧАСТНЫЙ ДЕТЕКТИВ ТАТЬЯНА ИВАНОВА. ДОЛЬЧЕ ВИТА ПО-РУССКИ» 12+
03.50 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 22.30 Новости
07.05, 16.45, 21.45, 00.25 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00, 00.05 Специальный репортаж 12+
10.25, 01.05 Профессиональный бокс. Алексей Папин против Дамира Белжо. Трансляция из Москвы 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «Ты в бане!» 12+
13.50, 04.35 «Футбол на все времена» 12+
14.25 Хоккей. OLIMPBET Чемпионат МХЛ. «Сибирские Снайперы» (Новосибирская область) – «Кузнецкие Медведи» (Новокузнецк). Прямая трансляция
18.40 «Мэнни». Документальный фильм 16+
20.30 Смешанные единоборства. UFC. Чарльз Оливейра против Ислама Махачева. Трансляция из ОАЭ 16+
22.35 Бильярд. «BetBoom Лига Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
02.10 Новости 0+
02.15 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Факел» (Новый Уренгой) – «Динамо-ЛО» (Ленинградская область) 0+
04.05 «Что по спорту? Кемерово» 12+
05.05 «Анатолий Тарасов. Век хоккея». Документальный фильм 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.45 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «АГЕНТСТВО «СПРАВЕДЛИВОСТЬ» (S) 16+
22.00, 00.05 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
02.25 Остросюжетный детектив «ЯРОСТЬ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ЛЮБЛЮ ОТЦА И СЫНА» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ ЛЕЧИТ» 16+
22.55 «Порча». «Отцовский долг». «На мосту» 16+
00.00 «Знахарка» 16+
00.30 «Верну любимого» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
01.50 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.40 «Тест на отцовство» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

04.40 «КАМЕНСКАЯ». «ИГРА НА ЧУЖОМ ПОЛЕ» 16+
06.30 «27 декабря – День спасателя России». Документальный фильм. Премьера! 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.00 «БОЛЬШАЯ ПЕРЕМЕНА». 2-я серия 12+
10.40, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05, 03.25 «КАМЕНСКАЯ». «УБИЙЦА ПОНЕВОЛЕ» 16+
15.00 Военные новости 16+
15.45 «КАМЕНСКАЯ». «Смерть ради смерти» 16+
18.50 «Морская авиация. Ударная сила океанов». Фильм 2-й. Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «УВОЛЬНЕНИЕ НА БЕРЕГ» 12+
02.10 «Маршал Конев. Иван в Европе» 16+
02.55 «Калашников». Документальный фильм 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 26 ДЕКАБРЬ – 1 ГЫЙНВАР

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Күптәнге танышларыгыз белән элемтәләрне ныгыту-торгызу чоры. Аларга шалтыратып яки язып, якынлашып килүче Яңа ел белән котларга, каникулда кунакка чакырырга онытмагыз. Өстәмә керем чыганаклары шулай гына табыла...

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Ел бетеп килә, дип артык туарылып китмәгез. Барча халык Яңа елны каршыларга әзерләнгән бер мәлдә вазыйфагызда тагын да ныгып, үсеп китәрдәй адымнар ясарга мөмкинсез. Ә моңа форсат чыгачак. Ничек кенә әле!..

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Бик күңелле Яңа ел сюрпризлары көтегез. Тирәгездәгеләр, мөлаемланыбрак китүегезне күреп, мактау сүзләре белән күңелегезне күрер. Курантлар сугар алдыннан искитмәле дәрәҗәдә матур хәбәр ишетерсез.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Хис-тойгыларның көчәеп киткән мәле. Дөньягызны онытып, гашыйк булып куюыгыз бар, ягъни... Бәйрәм алды керемнәре күп булса, киләсе елга зур гына планнар да кора аласыз.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Узып баручы елга эчтән генә йомгак ясап утырганда, хезмәттәшләрегез алдында бер башка үсеп китүегезне аңларсыз. Хәер, премияләр күләме дә раслар моны. Бәйрәм планнарын тагын да кызыклырак итеп үзгәртергә форсат чыгар.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Өс-башны, йөз-кыяфәтне карау өчен бик шәп мөмкинлекләр чоры. Телефоныгызда инде әллә кайчан онытылган номерларны бетергәндә, сәеррәк хатирәләр баш калкытыр. Бер дустыгыз әйбәт кенә яңалыклар белән куандырыр.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Кыюланып китеп, күңел түрендә еллар буе яшереп саклаган бер хыялыгызны чынга ашырып куярсыз. Гайбәтчеләрдән читтәрәк йөрегез: шәхси эшләрегезгә комачаулык ясаулары бар. Сөеклегездән Яңа елга бик шәп бүләк көтегез. Матди гына да булмастыр әле ул...

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Уңышлы атна. Эшләрегез күзгә күренеп алга китәр. Яңа елга керәбез дигәндә генә, акчалы эш тәкъдим итеп, уйга калдырырга мөмкиннәр.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Туганнарыгыздан күңелгә сары май булып ятардай хәбәрләр көтегез. Тормышыгызның уңай якка борылып маташуын сизеп сөенерсез. Гаять акчалы, күңелле һәм мул чор.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Байлык артыннан кумасагыз да, сезне ул үзе куып тотар. Әйе-әйе, байыйсылар алда әле... Кыскасы, Яңа елны күтәренке кәеф белән каршы алырсыз.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Елның соңгы көннәрендә кичектереп булмастай эшләр (алар әйбәт кенә акча китерәчәк чөнки) белән мәш килерсез. Көтмәгәндә генә элекке мәхәббәтегезне очратып, хатирәләр диңгезенә чумарсыз. Бәйрәм алдыннан дусларыгыздан үзегезне үсендереп җибәрердәй җылы сүзләр ишетерсез.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Ел азагы гаять әйбәт булачак. Ялгыз Балыклар бердәнберләрен табачак. Ә гаиләлеләр гүя бәхет диңгезендә йөзәчәк.

ЙӨРӘКТӘ ДӘ БАР ГАЕП

Соңгы арада күпләр ютәлдән азаплана. Бу аңлашыла да. Вируслы чирләр котырган чорга аяк бастык бит. Бу көннәрдә ютәлнең йөрәк авыруы билгесе булуына да инандырган аянычлы очраклар турында ишетергә туры килде. Без инде бармак аша гына карарга күнеккән йөткерү тагын нәрсәсе белән куркыныч? Ул нинди авыруларның билгесе булырга мөмкин?

Табиб-терапевт, невролог Эльвина ХАЛИТОВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Ютәл безне нинди чирләр турында кисәтә?
– Ютәл – кискен респиратор инфекцияле (ОРИ), вируслы авыруларның (ОРВИ) даими юлдашы. Әмма ул бик күп кенә башка авыруларның да билгесе булырга мөмкин. Йөткерү рефлексының рецепторлары борын, йоткылык, трахея, бронхларда гына түгел, алардан читтә – колак каналы, ашказаны һәм йөрәкнең тышкы тоташтыргыч тышчасында (перикард) да урнаша ала. Шуңа күрә кеше нерв, йөрәк-кан тамырлары системасы эшчәнлеге бозылганда, ашказанында хилафлыклар булганда, колак-борын авырулары вакытында да ютәлләргә мөмкин. Тәмәке тарту белән мавыккан кешедә еш кына хроник бронхит, үпкә авырулары күзәтелә. Алар вакытында да кеше бик нык йөткерә. Ютәл даруларның тискәре йогынтысы аркасында да пәйда була ала. Кан басымын төшерүче дарулар килешмәгәндә кеше, гадәттә, йөткерә башлый. Ютәл – туберкулез вакытында күзәтелгән төп билгеләрнең дә берсе.

:: Ютәл яман шеш билгесе дә була аламы?
– Әйе, үпкә яман шеше вакытында да көчле ютәл күзәтелә. Кызганыч, кеше, гадәттә, чир азып, соңгы стадиягә җиткәч кенә йөткерә башлый. Ашказаны-эчәк тракты, йөрәк-кан тамыры авырулары вакытында да ютәл пәйда була.

:: Йөрәк авырулары да йөткертә, дидегез. Аны салкын тигәннән ничек аерырга?
– Миокард инфаркты, миокардид вакытында үпкәләрдә кан йөрүдән туктап тора. Нәтиҗәдә кан бронхлар очындагы кечкенә «капчык» – альвеолаларга үтеп керә. Йөрәк авырулары вакытында йөткергәндә әнә шул сыеклык та чыга, какырыкта кан эзләре дә булырга мөмкин. Йөрәк авырулары вакытында күзәтелгән ютәл тын кысылу, һава җитмәү белән бергә уза. Ул ятып торганда тагын да көчәя. Шуңа кеше йоклый алмый тилмерә.

:: Салкын тиеп авырганда ютәл тиз генә бетми, атналар буена сузыла. Бу нәрсәсе белән куркыныч?
– ОРВИ вакытында ютәл озакка сузылса, аскы сулыш юллары ялкынсынырга, тора-бара ул бронхит, пневмониягә әверелергә мөмкин. Ютәл 3–4 ай дәвамында бетмичә тилмертсә, ул хроник бронхит, бронхиаль астмага ук әйләнә ала. Шуңа күрә вакытында чарасын күреп, ютәлне ахырына кадәр дәваларга кирәк.

:: Коры ютәл юеш ютәлгә әйләнсә, тизрәк тереләсең, диләр...
– Бу фикер белән килешеп бетмим. Коры ютәл, гадәттә, өске сулыш юллары зарарланганда күзәтелә. Аны юеш ютәлгә әверелдерү мәҗбүри түгел. Аскы сулыш юллары зарарланган очракта, какырыкның ябышкаклыгын киметә торган дарулар эчәргә кирәк. Бу йөткергәндә какырык яхшырак купсын өчен кирәк.

:: Ютәлне үз белдегең белән дәвалау куркынычмы?
– Әгәр йөткергәндә күкрәк читлеге авыртса, тын кысылса, тән температурасы күтәрелсә, какырыкта кан, яшькелт-сары үлек пәйда булса, ютәл вакытында сару кайнау, кикерү кебек билгеләр дә күзәтелсә, кеше кисәк ябыкса, аны үз белдегең белән дәвалау икеләтә зыянлы. Бу очракта кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ютәл озакка сузылган очракта да белгечкә күренү мәҗбүри. Сулыш юллары авыруларын кисәтү өчен, елга бер мәртәбә булса да табибта тикшеренеп, флюорография узу хәерле.

vk.com

Коры ютәл вакытында хәлне җиңеләйтү өчен табиб киңәшләре:

➤какырык яхшы купсын өчен, көн дәвамында чиста су эчеп торыгыз;
➤бүлмәләрне даими рәвештә җилләтеп, тузаннарны сөртү дә файдага булачак;
➤тәмәкедән баш тартыгыз;
➤коры ютәлне көчәйтүче даруларны да читләтеп үтегез;
➤физиотерапия, дренажлы массаж да файдалы;
➤баш астына мендәр куеп ятып тору да хәлегезне җиңеләйтәчәк. Иң мөһиме – башыгыз күкрәк читлегеннән югарырак торсын;
➤төнлә ютәл азапламасын өчен, ян-якка ятып йокларга тырышыгыз;
➤сөт һәм бал белән җылы су, чәй эчү дә ярдәм итми калмас;
➤ютәл бертуктамый борчыганда бөтнек тәме килгән суыра торган конфет та булыша.

Белә идегезме?

Кишер канны арттыра

Кишер ашагач, авыз куышлыгы микроорганизмнардан чистара. Ангина, стоматит, грипп булганда, кишер согы белән авызны һәм тамакны чайкыйлар. Томау төшкәндә, 4 өлеш кишер согына 3 өлеш үсемлек мае, 1 өлеш сарымсак согы кушып, борынга тамызалар. Аны көненә 3–4 тапкыр, өчәр тамчы тамызасы. Тавыш беткәндә, бер кишерне турап, ярты литр сөттә пешереп сөзәсе дә шуны җылы килеш аз-азлап эчәсе, тамакны чайкыйсы. Кишер согының тәме ошамаса, 1 кисәк лимон салырга да мөмкин. Кишер согы йөрәк мускулының арыганлыгын баса, яшелчәдәге кобальт тозлары исә кан басымын җайга сала, гемоглобинны яхшырта, B_{12} витаминын эшләп чыгарырга булыша. Миокард инфарктыннан соң 2–3 атна үткәч үк кишер согы эчә башларга ярый.

Алдырып кына бетми

Үт куыгын алдырганнан соң ташлар барлыкка килми дигән сүз түгел. Ташлар үт юлында тыгылырга мөмкин. Операция кичергән кеше сәламәтлегенә һәм туклануга аеруча игътибарлы булырга тиеш. Холестеринга бай ризыкларның таш барлыкка китерүе фәнни яктан күптән расланган. Шуңа күрә майлы ризык, атланмайдан баш тарту хәерле. Майлылыгы түбән булган сөт ризыкларына өстенлек бирегез. Кубрәк хәрәкәтләнегез. Операциядән соң 1,5–2 ай үткәч, көн саен 30–40 минут җәяү йөрергә кирәк. Йөзү бик файдалы. Иртән гимнастика ясауны гадәткә кертегез.

ҮЛӘННӘР ӘЛИФБАСЫ

Мүк җиләге. Кайнар су белән ясалган төнәтмәсен тәне кызышкан балага эчерәләр. 150 грамм җиләкнең согын сыгып, шуңа 1 аш кашыгы бал кушсаң, бер дигән эчемлек барлыкка килә. Тәмле дә, файдалы да.

Имбир. Күңелегез болганса, киптерелгән имбир чәйнәгез. Аннан чәй әзерләргә дә була. Баш авыртканда пычак белән кискәч чыккан согын чигәгә куярга мөмкин. Әмма аллергиясе булган кешеләргә имбир кулланырга ярамый.

Бәрәңге. Чи бәрәңге суы ашказаны авыруларына яхшы дәва. Моның өчен стаканның дүрттән бер өлеше кадәр чи бәрәңге суын ашар алдыннан ярты сәгать алдан эчү дә җитә. Чи бәрәңгене уып ясалган битлек балаларда күчеш чорында күзәтелә торган бетчәләрне бетерә.

ХӘТЕРНЕ ЯХШЫРТУ ӨЧЕН КҮНЕГҮЛӘР

✱һәр хәрефкә сүз әйтеп, алфавитның бар хәрефләрен тиз генә кабатлап чыгыгыз (а-алма, б-балта...);
✱бер хәрефкә башланган 20 сүз әйтегез һәм аларны номерлап барыгыз (1 – кулмәк, 2 – китап, 3 – кунак...);
✱бер минут, бер сәгать элек яки кичә нәрсә эшләгәнегезне, соңгы өч көндә иртән нәрсә ашаганыгызны искә төшерегез;
✱әгәр уң кулыгыз белән язсагыз, сул кул белән язып карагыз, ә сулагайлар, киресенчә, уң кул белән язсыннар;
✱караңгы бүлмәдә йөреп карагыз, ул хәтерне, игътибарны арттырып;
✱укуга, эшкә барганда моңа хәтле таныш булмаган юлдан йөрсәгез, баш мие эшчәнлеге яхшырыр;
✱кибеткә кергәч, калькулятор кулланмагыз. Хәтердән генә кушу, алу баш мие эшчәнлеген яхшыртыр.

НӘРСӘ АШАРГА?
✱Хәтер яхшы булсын өчен, көн саен кишер кырып, аны үсемлек мае белән ашарга киңәш ителә.
✱Ананас согы да хәтерне яхшырта.
✱Чит телләр өйрәнгәндә лимон ашау, әфлисун согын даими куллану ярдәм итә.
✱Авокадо, суган, чикләвек, кәбестә, креветкалар да баш мие эшчәнлеген яхшыртып, хәтерне ныгыта.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

ЧЫРШЫ СЕРЕ – ИСЕНДӘ

Яңа ел алдыннан күпләр чыршы сайлау белән мәшгуль. Кайчак чын чыршы саргая, ә ясалмасы тәмсез ис чыгарып һәм коелып кәефне кыра. Мондый хәлләрне булдырмас өчен, Роспотребнадзор киңәшләрен белеп тору комачау итмәс.

vk.com

ЧЫН ЧЫРШЫ. Ни генә дисәң дә, күпләр Яңа елны чыршысыз күз алдына китерә алмый. Кайчак чынын алсаң саргая, ясалмасы әллә нинди тәмсез исләр чыгара, коела. Шундый хәлләргә юлыкмас өчен, Роспотребнадзор киңәшләрен истә тоту файдага булыр.

Чын чыршыны чыршы базарыннан яки урманчылыктан алырга кирәк. Сатучының питомник агачларын сатуга рөхсәте бармы-юкмы икәнлегенә дә игътибар итегез. Мондый чыршыны рөхсәтсез сатучы кулыннан алмавың хәерле.

«Тере» чыршыны декабрьнең егерменчесеннән соң алсаң яхшы. Иртә алган чыршы бәйрәмгә кадәр коелып бетәргә мөмкин. Агачны сайлаганда аның кайрысына игътибар итегез: ул туры, калын, чатнамаган булырга тиеш. Ботаклары да, энәләре дә сыгылмалы булу зарур. Чыршыны тикшереп алуның тагын бер ысулы – аны төбе белән җиргә бәреп карагыз. Энәләре бик нык коелса, андый агачны алмавың хәерле. Берничә ылысны учыгызда уып карагыз, аннан тәмле ис килеп торырга тиеш. Әгәр чыршының энәләре каты, кипкән, сынып китүчән һәм исе юк икән, бу аның күптән киселгән булуын аңлата.

Чыршыны урамнан яки урманнан алып кайтуга өйгә алып кермәгез, 2–3 сәгать балконда яки башка салкынча урында тотканнан соң гына өйгә алып кереп бизәгез.

ЯСАЛМА ЧЫРШЫ. Соңгы вакытта күпчелек ясалма чыршыларга өстенлек бирә. Сатып алганда ясалма чыршының ботакларына игътибар итәргә кирәк. Алар яхшы итеп беркетелергә һәм селкенеп тормаска тиеш. Иснәп карарга да онытмагыз, аннан тәмсез ис килмиме? Шулай ук ылысларын әкрен генә тартып карагыз, алар өзелмәскә тиеш. Аннары чыршының ылыслары үскән уңайга каршы учыгызны шудырып карагыз. Сыйфатлы ылыс тиз генә үз формасына кайтачак һәм коелмаячак. Шулай ук чыршы ботагы очларында тырпайган һәм чәнчи торган чыбык ише әйберләр булмаска тиеш.

Сайлау

✓ Энәләр сары булмаска һәм коелмаска тиеш.
✓ Агач нечкә булмасын (1,5 метрлы агачның диаметры 6 см чамасы була).
✓ Кайрысында һәм ботакларында зарарланган урыннар булмасын.
✓ Агачтан тәмле ылыс исе килеп торсын.



Урнаштыру

✓ Җылыткычлардан ераграк урнаштырыгыз.
✓ Урнаштырыр алдыннан кискән урынын яңадан бер кисеп алыгыз. Анда каралган урыннар, күгәрек һәм гөмбәчекләр булмасын.
✓ Агачның чүлмәккә утыртылганын сатып алырга да була. Бәйрәмнән соң балкон яки салкынча урынга куеп торып, аны язын җиргә утыртырга мөмкин.

Хуҗабикәгә

КҮПМЕ САКЛАРГА ЯРЫЙ?

Чисталык саклау өчен тотыла торган «химия»нең күбесе вакыты чыккач яраксызга, хәтта куркынычка да әйләнергә мөмкин икән.

Водород перекисе. Аны еш кына йорт шартларында тапларны бетерү өчен кулланалар. Водород перекисен салкынча, караңгы урында ярты ел сакларга кирәк. Аннан соң ул үзенең «көч»ен югалта. Шунлыктан аның кечкенә савыттагыларын алу яхшырак.

Савыт-саба юа торган гель. Аның яраклылык вакыты – 12–18 ай. Хәтта ябык килеш тә ул үзлеген бер елдан соң югалта. Гель сыеклана, юу үзлеге дә начарлана.

Кер юу порошогы. Ачканнан соң кер юу порошогы ярты елдан соң, ә ачылмаган кабында бер елдан соң бозыла башлый. Кер юу порошогының яраклылык вакыты чыккан булса, ул керләрдән юылып бетми, нәзберек тиреле кешеләрдә ялкынсыну китереп чыгарырга мөмкин.

Керләр өчен кондиционер. Ябык савытта йомшарткыч үзлеге өч елга кадәр саклана. Ачканнан соң, бер ел узгач, файдалы үзлеген югалта. Кондиционер савытын кулланыр алдыннан бераз селкетеп алырга киңәш ителә.

Тәрәзә чистарту чаралары. Аларның яраклылык вакыты – 24 ай. Бу аның савыты тышындагы шартлар үтәлгәндә генә. Дөрес кулланмаган очракта аның составындагы нашатырь спирты баш авыртуга сәбәпче булырга, күзгә зыян салырга мөмкин.

Сода. Ачылган савыттагы соданың яраклылык вакыты – 6–8 ай. Аның сыйфатын лимон согы яки уксус ярдәмендә тикшереп карарга була. Содага икесенең берсен салгач күбекләнә икән, димәк, әле яраклы диган сүз.

Тәмле булсын!

«Чыршы күркәләре» десерты

Нәзилә ТУЧЫБАЕВА рецепты

Кирәк: *130–150 г печенье, 50 г атланмай, 1 аш кашыгы какао, куертылган сөт (кайнатылганы да ярый), солы лачаулары.*

Печеньены блендерда ваклатабыз. Шуңа какао, атланмай, куертылган сөтне кушабыз. Масса нык каты да, нык сыек та булырга тиеш түгел. Учта кыскач, формасын сакларга тиеш. Шул массадан 5–6 конус ясыйбыз да лачауларны астан өскә таба, күркә формасына китереп җыеп менәбез. Аннары шикәр пудрасы сибеп суыткычка куябыз.

Белеп тор!

Мандарин сайлыйбыз

Яңа ел табынын һәм, гомумән, кышны мандаринсыз күз алдына китереп булмый. С витаминына кытлык үзен сиздерәме, кибеткә керүгә күз шуңа төшә. Аны сайлау буенча берничә киңәшне истә тотсагыз, бер дә комачау итмәс.

- ▶ Мандарин сайлаганда, аны кулыгызга тотып, бераз сыпырыгыз һәм иснәп карагыз. Саф, тәмле ис килә икән, димәк, мандарин бик яхшы диганне аңлата.
- ▶ Аны бераз гына учыгызда кысып караганда ул үз халәтенә тиз генә кайта икән, бу шулай ук мандаринның бозылмаган булуын, әллә кайчаннан кибет киштәсендә ятмавын аңлата.
- ▶ Мандарин кабыгыннан бераз аерылган сыман булырга тиеш. Кабык эчендәге җимешенә тыгыз булып берегеп тора икән, димәк, мандарин йә өлгереп җитмәгән яки кибә башлаган диган сүз.
- ▶ Яхшы мандарин тыгыз һәм коры булмый. Сусыл җимешне кулга алгач, аның эчендәге авырлыгы сизелеп торырга тиеш.
- ▶ Һәрвакыт мандаринның төсенә игътибар итегез. Яшел мандарин әче була. Шуңа янып торган җирән төстәге мандариннарны сайларга тырышыгыз.
- ▶ Әгәр тәмлелегенә шигегез булса, башта бер-икене генә алып ашап карагыз.
- ▶ Күләменә килгәндә, өлкәннәргә көненә – 5–6, ә балаларга 1–2 мандарин ашарга ярый.

Матур бул!

КУЯНГА ОШАРЛЫК БУЛСЫН

2023 ел – Кара су куяны елы. Аны каршылаганда нинди төсләргә киемнәргә өстенлек бирергә кирәк соң?

Куян – тыныч, сак, дустанә, тотнаклы хайван. Яңа ел образын сайлаганда да әлеге сыйфатларга өстенлек бирергә куша стилистлар. Бәйрәмгә сайлаган киемегез дә кычкырып тормый торган, сезнең табигый матурлыгызны тагын да ача торган булырга тиеш. Төп төсләр – кара һәм куе зәңгәр. Куянның яшәү рәвешенә туры килә торган – яшел, ком, гәрчич төсен сайласагыз да була. Алтынсу, көрән, сорының бөтен төсмерләре дә бу ел символына ошаячак. Ирләргә, костюм кигәнчә, уңайлы кием сайларга киңәш итә стилистлар.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

БИСМИЛЛАСЫЗ ЧАЛЫНГАН МАЛ ХӘЛӘЛ ТҮГЕЛ

Кешенең физик яктан да, рухи яктан да сәламәтлеге аның нинди ризык ашавына бәйле булуын берәү дә инкарь итмәс. Мөселман кеше ашыйсы ризыгына аеруча игътибарлы. Хәләл ризык ашар өчен, хәләл мал үстерү дә мөһим. Ислам дине таләпләренә туры китереп, ничек итеп терлек чалырга? Сугым вакытында нинди дога укырга?

«Шамил» мәчете имам-хатыйбы Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИНОВка кызыксындырган сорауларны бирдек.

:: Исламда терлек чалуга нинди караш? Күпләр хәтта корбан чалуны да кыргыйлык дип саный бит.

– Ислам дине ашау-эчү мәсьәләсенә бик җитди карый. Ягъни нинди ризыкны ашарга ярый, кайсын юк – барысын да билгели. Пәйгамбәребез (с.г.в.) шундый кыйсса да сөйләп калдырган. Сәфәрдә чакта бер бәндә сусыз-ризыксыз калган, үлем хәленә җитеп, кулларын күкләргә күтәреп: «Раббым, ярдәм ит!» – дип эндәшә, ди. Ләкин аның эчкән суы – хәрам, ашаган ризыгы – хәрам, кылган гамәлләре – хәрам, кигән киеме хәрам икән. Гомумән, гомере дә хәрам белән сугарылган. Ничек инде аңа Раббыбыз җавап бирсен? Ягъни кешенең дөньяда җан һәм тән ягыннан сау булуы нинди эчемлек эчүенә, нинди ризык ашавына барып тоташа. Минемчә, бу фикер белән фән дә бәхәсләшмәс, акыл ияләре дә каршы килмәс. Эчебезгә нинди ризык керә – тышкы һәм эчке халәтебез шуннан тора.

Малларны чалуга килгәндә, дин күзлегеннән караганда, хайваннар арасында чалырга тыелганнары да, рөхсәт ителгәннәре дә бар. Тыелганнар рәтенә, әйтик, дуңгыз итен кулланy, ерткыч хайваннарны чалып, алар белән ризыклану керә. Үлән белән тукланган, ерткыч булмаган хайваннарның күбесе исә шәригатьтә рөхсәт ителә.

Күпчелек корбан чалуга да каршы, дигәннән. Күпчелеккә карап кына хакыйкать билгеләнми бит әле. Кайдадыр, нииндидер бер җирдә күпчелек наркотикны яхшы дип таба, ди, гаепсез кешене рәнҗетүне дә, угрылыкны да гадәти хәл дип, табигый дип саный, ди. Корбан чалу шәригать тарафыннан саваплы гамәл булып санала.

:: Хәләл ит нинди була?

– Ит хәләл булсын өчен, бердән, ул рөхсәт ителгән хайваннар рәтенә керергә тиеш. Тагын бер шарт – малны бугазлаган вакытта «бисмилләһи, Аллаһу әкбәр» дип әйтергә. Бисмилласыз чалынган малның ите хәләл булмый.

:: Нинди малның итен ашау тыела?

– Ерткыч хайваннар барысы да тыела. Аулап, башка хайваннарны тырнаклары белән өзгәләп ашый торган хайваннарны кулланy ярамый. Дуңгыз итен ризык итеп куллану да тыела. Ерткыч булмаса да, ишәкне чалып, иткә кулланырга ярамый.

«ВТ» архивыннан

:: Мөселман кеше дуңгыз суюда катнаша аламы?

– Ачык рәвештә Коръәндә янсә пәйгамбәребез (с.г.в) хәдисләрендә «дуңгыз чалуда катнашсагыз, гөнаһ булыр» дигән бер генә сүз дә юк. Ләкин тыю булмаса да, бу эштән булдыра алганча читләшү киңәш ителә.

:: Шәригать кушканча мал чалу кагыйдәләрен искәртсәк иде.

– Гомуми әйткәндә, малны чалыр алдыннан аны тынычландыру кирәк. Аякларын бәйләргә, кыйблага каратып, бугазы белән яткырырга. Сөннәткә туры китереп эшләргә тырышырга. Чала торган пычакны яхшы итеп кайрарга кирәк. Бугазлаган вакытта «бисмилләһи, Аллаһу әкбәр» диярргә.

:: Мал суйганда тагын нинди дога укырга?

– Бердәнбер дога – «бисмилләһи, Аллаһу әкбәр». Корбан чалганда исә аерым догалар бар.

:: Бәрәкәтле, хәләл мал үстерү өчен, хуҗа кеше нәрсә эшли ала?

– Малның хуҗасы булдыра алганча хайваннарны хәләл ризык белән тукландырырга тиеш. Урланган печән, тиешсез ризыклар ашатырга тиеш түгел ул.

!
✓Аз малың, күп куанычың булсын.
✓Азапсыз килгән мал затсыз була.
✓Тамгалы мал югалмас.
✓Бер үгезнең мөгезенә суксаң, мең үгезнең тоягы шакылдар.

Гыйбрәт ал!

Балта кыйссасы

Бер кеше өй алдында балтасын югалткан. Эзләмәгән җире калмаган. Капка төбенә чыгып караса, анда күрше малае йөри икән. Малайның һәрбер адымы аның карак икәнен дәлилли кебек. «Мөгаен, ул урлагандыр инде», – дип, капка алдына чыга башлаган хуҗа үз балтасына абынып егыла. Балтасын тапкач, капка төбендә йөргән күрше малаеның карак икәнлегенә ишарә итә торган бер генә сыйфатны да тапмый.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) дә: «Башкаларны гаеп итәр алдыннан карагыз, үлчәгез, гаепсезне гаеп итә күрмәгез. Сәбәпсезгә берәрсен гаеп итә башласагыз, ул иң ялган сүздән булыр», – дип әйткән бер хәдисендә.

pinterest.com

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кайнар да, салкын да булмасын

Саулыкның нигезендә дөрес туклану ята. Бу хакта динебездә дә әйтелә. Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) бу хакта түбәндәге мәгълүматны китерә:

• озак вакыт ашалмыйча калган ризыкны ашамагыз;
• ризыкны бик кайнар яки салкын булганда ашамагыз;
• кулларны ашар алдыннан, ашагач юыгыз;
• эч тулганчы ашамагыз;
• ашаган арада суны күп эчмәгез;
• ялгыз гына ашамагыз;
• арыган булсагыз, баллы, татлы ризык ашап кую кирәк;
• айга бер көн булса да ураза тоту хәерле. Тән ял итәр.

Йәгез, бер дога!

ЮЛГА ЧЫККАНДА УКЫЛА

«Аллааһүммә иләйкә тәвәҗҗәһтү вә бикәгътәсамтү, Аллааһүммә әкфинии мәә әһәммәнии вә мәә ләә әһтәммү ләһү. Аллааһүммә зәввиднит-тәкъвә вәгъфир лии зәнбии вә вәҗҗиһнии лил-хәйри әйнә мәә тәвәҗҗәһтү».

Мәгънәсе: «Аллаһым! Сиңа юнәлдем, Сиңа сыендым. Аллаһым! Шикле һәм шиксез нәрсәләрдән миңа таяныч бул. Тәкъваны миңа ризык әйлә, Аллаһым! (ягъни Сиңа гыйбадәтләр кылып, рухыма азык табыйм) Аллаһым! Гөнаһларымны гафу ит һәм кая гына китсәм дә, мине һәрвакыт хәерле эшләргә юнәлт, йә Раббым!»

kzn.ru

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Гаиләдә белем бирү турында

Бүген республикада 2500дән артык бала өйдә белем ала. Аларның кайберләре Мәскәү, Санкт-Петербургтагы хосусый мәктәпләргә беркетелгән. Илсур Һадиуллин әйтүенчә, өйдә укыту – үзе бер проблема.

– Закон әти-әниләргә балаларын өйдә укытырга мөмкинлек бирә. Без аңа каршы килә алмыйбыз. Әмма балаларны мәктәптән аерырга ярамый. Укучылар мәктәптә бер-берсе белән аралашырга, тормышка яраклашырга өйрәнергә тиеш, – диде министр. – Өйдә укучылар барлык очракта да гади мәктәпкә беркетелми. Ә хосусый уку йортларының кайберләренең аккредитациясе юк. Аннан башка балага аттестат бирергә хаклары юк. 9 нчы, 11нче сыйныфларда исә имтиханнар тапшырырга кирәк. Шуңа күрә балаларга мәктәпкә кире кайтырга туры килә. Балалар кызганыч. Әти-әниләр репетиторлар ялларга мәҗбүр. Безнең бурыч – балаларны мәктәпләргә кайтару.

Казанда яшәп, дүрт бала тәрбияләүче Энҗе Кадыйрованың ике баласы – өйдә, олысы мәктәптә 11 нче сыйныфта укый.

– Улыбыз Азаматның сөйләмендә кимчелекләр булгач, аны өйдә укырга күчердек. Сыйныфташлары көләр, дидек. Хәзер ул 4 нче сыйныфта укый. Бу форма безгә ошады. Быел 1 нче сыйныфка барган кызыбыз өчен дә гаиләдә укыту формасын сайладык. Без качып йөрмибез. 156 нчы мәктәпкә беркетелдек, шунда барып, имтиханнар тапшырабыз, – ди ул.

Аның әйтүенчә, өйдә укысалар да, балаларның бер минут та буш торырга вакыты юк. «Мәктәптә барысын да укытучы чәйнәп диярлек аңлатса, өйдә уку күпкә авыррак. Бала мөстәкыйль булса, бу форма әйбәт. Әмма ул кушканны үтәми икән, бу очракта өйдә укытуга күчерү – зур хата», – ди Энҗе ханым.

Хисап эше турында

Яңа уку елы башында да укытучыларның хисап эше кимеячәк дип тынычландырганнар иде, әмма ул әлегә сүздә генә калган, күрәсең. Моның шулай икәнен безгә Арча районы укытучысы Нурисә Зарипова да дәлилләде.

– Өйгә кайткач, электрон журналлар тутырып, вакыт үтә. Бер көнне дәрескә әзерләнеп, иртәнге сәгать 3кә кадәр утырдым. Бәлкем, эшне оештыра белмәүдә үзем дә гаепледер. Әмма хисап тутырулары киметергә кирәк, – ди Нурисә ханым.

Илсур Һадиуллин очрашуда министрлыкның укытучыларның хисап эшен киметү бурычын куюын әйтте.

– Без укытучыларның белем бирү урынына кәгазь эше белән шөгыльләнүен теләмибез. Әгәр министрлыкка килгән барлык хатларны мәктәпләргә юлласак, аларның эшләргә вакыты калмаячак, – диде министр.

Министр кәгазь эшен киметү буенча «кайнар элемтә» булдырылуын да искәртте. Тик анда ай ярым эчендә нибары 12 укытучы гына шалтыраткан.

Тиздән Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының сайтында яңа кушымта да булдырылачак. Анда укытучыга кирәкле барлык мәгълүматлар урнаштырылачак.

Мәктәпләрне кыскарту турында

Журналистлар авыллардагы кечкенә мәктәпләрне ябу турында да кызыксынды.

Моннан ике ел элек Актаныш районының Яңа Кормаш мәктәбендә тугызъеллык мәктәпне башлангычка калдырганнар. Шуннан соң ике укытучы белем биргән, узган ел берсен кыскартканнар.

– Мәктәпне кыскартып, дәрес эшләмәделәр. 19 бала бар иде бит. Балаларны күршедәге Татар Суксуы мәктәбенә йөртәләр хәзер. Узган ел мине ноябрь аенда эштән кыскарттылар. Мин аңлыйм: дүрт баланы ике укытучы укыта алмый. Тик 29 ел башлангыч сыйныфларга белем биргән укытучы буларак, миңа эштән китү бик авыр булды. Хәзер клубта мөдир булып эшлим. Мәктәп авылның тоткасы иде, – диде Эльмира Шәймөхәммәтова.

– Әйтик, Кукмара районында мәктәпләрне бергәләп саклыдык. Башка районнарда да андый очраклар бар. Әгәр балалар бар икән, безнең бурыч – мәктәпне саклау. Башлангычта бер генә бала булса да, аны сакларга тәкъдим итәбез. Мәктәп булмаса, авылның киләчәге юк. Республикада хәзерге вакытта 99 башлангыч азкомплектлы мәктәп бар, – диде Илсур Һадиуллин.

Сәрия МИФТАХОВА

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

БЕЗГӘ КИЛЕП КҮРЕГЕЗ!

«Татар-информ»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кунакка урын түрдән

Чир китә, гадәт кала, дигәндәй, OneTwoTrip хезмәте мәгълүматларына караганда, Татарстан башкаласы Россия шәһәрләре арасында Яңа ел каршы алу һәм каникул өчен кызыклы калалар исемлеге бишлегенә кергән. Сораштыруда катнашучыларның 67 проценты Казанның бай тарихлы булуын билгеләп үткән. Әнә шуның өчен үз итәләр дә икән инде башкаланы. Чагыштыру өчен: Мәскәүне – күңел ачу чаралары күплеге, Санкт-Петербургны – тарихи урыннары, Калининградны матурлыгы, рәхәт һава торышы өчен яраталар, диелә сораштыруда.

Татарстанның һәм Казанның туристик потенциалы бар һәм моның белән берәү дә бәхәсләшмәс. Шуңа да аны (хәзерге вазгыятьтә аеруча) туристларны җәлеп итә торган төп үзәкләрнең берсе итеп күрергә телиләр. Һәрхәлдә, кунакчыллык өчен җаваплы кешеләр шул хакта хыяллана.

Казан Башкарма комитетының Туризмны үстерү комитеты директоры Дарья Санникова әйтүенчә, туристлар арасында иң популяр урыннар булып, гадәттәгечә, Казан Кремле, Бауман урамы, Иске Татар бистәсе, музейлар, аквапарк, Кремль яр буе кала бирә. Узып баручы елның 9 аенда башкалага 2251600 кеше килгән. 2030 елга зур бурыч куялар: Казанны 5 млн турист күрергә тиеш. Дарья Санникова моны мөмкин ди. Халыкара чаралар, тәҗрибә алмашу, тәмле сыйларга, цифрлы мөмкинлекләргә таянмакчылар.

Татарстан туристлык агентлыклары ассоциациясе президенты Рамил Мифтахов та бу санга ирешергә мөмкин дигән фикердә. Булган инфраструктураны камилләштерергә, яңа туристик маршрутлар уйлап табарга кирәк нибары. Тимер юл, аэропортның да куәте җитәрлек. Моңа өстәп, ассоциация президенты фикеренчә, М12 юлы автобуста сәяхәт итүчеләрне арттырачак.

– Чикләүләр булганга күрә, эчке туризм үсештә. Иркенәергә кирәкми. Берничә елдан бу чикләүләр юкка чыгарга мөмкин. Хәзер исә сәяхәт киеренкелекне басарга, стрессны киметергә ярдәм итә. Кыска вакыт аралыгында якын-тирә шәһәргә барып кайту ихтыяҗы һәм мөмкинлеге бар бит кешеләрдә, – ди ул.

Туризм буенча дәүләт комитеты башлыгы Сергей Иванов Татарстан халкына кышкы чорда туристлар күплегенә гаҗәпләнмәскә кушты. Туристлар агымын 10–11 процентка артыр дип фаразлыйлар. Былтыргы саннар белән чагыштырганда, билгеле. Ун көнлек ялларда 170–180 меңләп кешене кунак итмәкчеләр. Сергей Иванов әйтүенчә, бу – туризм инфраструктурасы өчен ярыйсы гына сынау. Әйтик, кунакханәләр тулы диярлек. «Декабрьнең ахыргы көннәрендә шәһәрнең үзәк өлешләрендә, бөтен туристик урыннарда бик күп кунаклар булачак. Без моңа әзер», – ди комитет җитәкчесе.

Кунакханә димәктән, Россиядә туристлар өчен кунакханәдә йә башка торак урыннарда урнашу бәясе 35 процентка арткан да әле. Фатирларын көнләп арендага биреп торучылар да бәя күтәргән. Бәя ярышында Татарстан башкаласы, Мәскәү һәм Санкт-Петербургны да уздырып, беренчелектә тора.

Икмәк тә бар, тамаша да

Татарстанда яшәп тә, аның күп кенә кызыклы урыннарына барырга вакыт таппаган кешеләр байтактыр. Кышкы каникул – бу хатаны төзәтер өчен менә дигән мөмкинлек. «Бездә ни өчен ял итәргә кирәк?» дигән сорауга җавап эзләп карыйбызмы?

ТАРИХ. Татарстанның һәр почмагының тарих исе килә. Шәһри Казан белән генә чикләнмичә, якын-тирә шәһәр-районнарга чыгып, белем эстәргә була. Әйтик, **Болгар**ның апак карга күмелгән «Ак мәчете»н, **Зөя утравы**ндагы агач музеен барып күрергә. **Балык Бистәсе**нең борынгы ханлыклар төбәгә булуын да күпләр белмидер әле. Татарстанның географик үзәге саналган **Чистай**да архитектура, әдәбиятка бәйле урыннар күп. **Тәтеш** сәүдәгәрләр йортлары, музейлары белән данлыклы **Биләр** – академиклар ватаны, борынгы истәлекләр саклаган урын буларак билгеле. **Арча** – Тукайны биргән төбәк. **Азнакай**ның – Чатыр, **Кама Тамагы**ның Лобач тавы бар. **Алабуга** курганнарында безнең эрага кадәр яшәгән фин-угор кабиләләренең каберлекләре белән танышырга була. **Саба** урманнары дендрарие белән дан тота.

ЯҢА ХИСЛӘР. Үзегезне сынап, тикшереп карыйсыгыз килсә, **Кама Тамагы**на барыгыз. Биредә мәгарәләр, шахта штольнялары сакланып калган. Теләге булганнарга махсус экскурсия дә оештыралар. Мәгарәләрнең бик киңнәре дә, тарлары да бар. Кышкы экскурсия берәүне дә битараф калдырмас!

Казанга әйләнеп кайтсак, «Урам» экстрим-паркы, Алафузов фабрикасын телгә алырга кирәк. Тынычлык яратучылар Милли китапханәгә сыена ала. Казаннан ерак булмаган Зәңгәр күлне дә күпләр ишетеп беләдер. Кышын да боз белән капланмый торган бу урында коенып, бер кочак хис-кичерешләр алып кайтырга мөмкин.

Балтачның Каракүле дә кызыклы. Аны күчеп йөри торган сулык дип тә атыйлар. Тирәнлеге турында әле дә бәхәсләшәләр. «Су үгезе» дигән татар Лох-Нессы да шушында яши, ди.

ЯҢА ТӘМНӘР. Татарстан сыйларын авыз итәр өчен генә дә махсус гастросәяхәт оештырырга тәкъдим итәбез. Чәкчәк, өчпочмак кына түгел бит әле бездә! Һәр җирлек үз сые белән каршы алырга әзер. Әйтик, **Кама Тамагы**на килеп, сыр, балык ашыннан авыз итми калмагыз. **Зөя утравы**нда «Кояш эчемлеге», икмәк эчендә кызыл аш, калын коймак тәкъдим итәләр. **Мамадыш**та да сыр, балык ризыкларын ашап карарга була. **Кукмара**да лимонад, борай бәлеше белән сыйлыйлар. **Кайбыч** районында юкадан авыз иттерәләр.

СПОРТ. Таулардан тыш, Татарстанда чаңгы, спорт, чана шуу өчен махсус урыннар җитәрлек. Әйтик, **Зәй**нең «Федотово» үзәгендә алты төрле трассада чаңгы һәм сноубордта шуарга мөмкин. **Кукмара**да «Бакыр тау» шуны ук тәкъдим итә. Бушлай мастер-класслар да каралган. Тюбингта шуарга мөмкин. **Әлмәт**тә «Ян» дигән комплекста да шулай ук. **Биектау**дагы «Каскад» трассасы балалар һәм кышкы спорт төрләрендә әле яңа кеше булганнар өчен кулай.

Спорт сөючеләр **Саба**дагы «Сабантуй» комплексында пейнтбол уйнарга, атта йөрергә, атарга өйрәнә ала. Ат дигәннән, **Лаеш, Лениногорск, Питрәч, Түбән Кама, Алабуга**да да махсус үзәкләр бар.

ЗАМАНЧА ЯЛ. Соңгы елларда ил күләмендә дә, Татарстан буенча да шәһәр читендә ял итү популярлаша башлады. Глэмпинг дигән сүз хәзер ят түгел. Республикада шундый 19 җир бар. Аларда да Яңа ел программалары каралган. Төрле кесәгә ярарга тырышканнар.

ӘКИЯТ ИЛЕ. **Арча**ның «Могҗизалар урманы» туристлар арасында аеруча популяр. Биредә Кыш Бабай резиденциясе бар. Яңа елга махсус программа әзерлиләр. Бу урманда Шүрәле дә, Кар кызы да, башка әкият каһарманнары да яши. Гаилә белән ял итү өчен яхшы мөмкинлек.

Үзем күрдем

Карлы ел фасылын үз итмәсә дә, «ВТ» хәбәрчесенең төп яллары кышкы чорга туры килә. Өч төрле ял ысулын үзе дә сынап карады.

Кама Тамагы

«КАМСКИЙ ТРОФЕЙ». Алдан ук кисәтеп кую зарур: биредә ял итү өчен акча янчыгының бик калын булуы кирәк. Эко-комплекс саналган бу җир, бердән, үзенең искиткеч табигате белән җәлеп итә. Икенчедән, ул бик заманча. Татарстанда булып та үзеңне читтә кебек хис итәргә мөмкин. Бер төн куну 6500 сумнан башлана. Бу бәягә иртәнге аш та керә. Моннан тыш биредә кар чанасында (снегоход) йөрергә, балык тотарга, мунча керергә мөмкин. Өстәмә акча түләп, билгеле. Тышта урнашкан җылы бассейн исә тәүлек әйләнәсе эшли. Ул кунаклар өчен ачык. VIP-йортларда исә, матур манзарадан тыш, үз ишегалды һәм фуракосы (агачтан ясалган коену мичкәсе) бар.

Питрәч районы

«ДИКАЯ ДАЧА» ГЛЭМПИНГЫ. Бу урынга шәһәр ыгы-зыгысыннан качып, табигать белән бергә-бер калу өчен киләләр. Җылы юрталарда яшисе. Табигать искиткеч. Тау шуарга, мунча керергә була. Ашау-эчү – үзеңнән. Бер көн юртада яшәү бәясе 4900 сумнан башлана.

Югары Ослан районы

«СВИЯЖСКИЕ ХОЛМЫ». Кышкы спорт төрләрен яратучылар әлеге курортны аеруча үз итә. Дөрес, быел бәяләр шактый «тешли». Биредә спа-үзәктә ял итәргә, бильярд уйнарга да мөмкин. Өстәвенә курорт бик матур урында урнашкан. Бер төн куну бәясе 6100 сумнан башлана. Бу бәягә иртәнге аш та керә. Туклану – «швед өстәле» тибында.

100 ЯШЬЛЕК САИМӘ ЯКУПОВА:

«СИЗЕЛМИ ДӘ ҮТТЕ ГОМЕР»

Озак яшәү сере – сабырлык! Казанның Осиново бистәсендә гомер итүче Саимә Якупова шулай ди. Күптән түгел 100 яшен тутырган әбекәй, тормышына шөкер итеп, язмышына рәхмәт укып, кызы Фәнисә тәрбиясендә яши. Апас районының Шыгай авылында туа ул. Шунда яши, гаиләле була, балалар үстерә. Казанга әле олыгаеп киткәч кенә күченә.

Якуповларның шәхси архивыннан

– Безнең тормыш җиңел булмады. Иркәләнеп утырмадык, кызым, – ди әбекәй. – Сабый чагымнан әти-әнисез калган бала мин. Күпне күрергә туры килде. Ятимлек ачысын да күп татыдым, ачлыктан да интектем. 15 яшемдә бер ялгызым калып, тормыш арбасын тарта идем инде. Үксеп елаган чаклар, язмышка үпкәләрем дә күп булды. Әти-әнисез калгач, яшемне күп түктем. Әмма бар хәсрәтборчуны сабырлыгым җиңә алды. Шушы яшемә җитүемә дә холкым сәбәпче.

Саимә әби гомере буе колхозда эшли. Бер эштән дә куркып тормый. Ни кушсалар, шуңа тотына. Басуда да бил бөгә, фермасында да эшли, бригадир да була. Саимә әби яшь чагында бик чая була. Эшкә батырлыгы янына җырга-моңга сәләте дә килеп кушыла. Әнә шуңа бар борчуларын оныта да инде ул. Күңелен җыр белән баса. Авыл сәхнәсеннән төшми Саимә. Спектакльләрдә дә уйный.

– Ул елларда авыр булса да, мин әле дә яшьлегемне сагынып искә алам. Без боегып, елап утырмадык. Үз күңелебезне үзебез күтәреп яшәдек. Тормыш булгач, борчуы да, күңелсез хәбәре дә килә тора инде аның. Әмма уздырып җибәрә белү кирәк, – ди ул.

Үзе ятимлек ачысын күргәнгәме, Саимә әби, хатыны вафат булган авылдашына кияүгә чыгып, дүрт баланы әниле дә итә. Хәнифулла абый белән уртак ике балалары туа. Саимә әби һәр баласын бертөрле яратып үстерә. Иренең ике малае, ике кызы да «әни» дип эндәшә аңа. Бик тату яшиләр. Инде иренең ике улы вафат икән. Әмма ике кызы бүген дә әниләренең хәлен белеп, туганнары белән аралашып яши. Саимә апа белән Хәнифулла абыйның уртак балалары Фәнис белән Фәнисә әйтүенчә, беркайчан да чит булмаган, бертуганнар кебек үскән алар.

– Без бер-беребезгә бик газиз. Алты туган бер оя булып үстек. Моның өчен әти-әнигә рәхмәт, – ди Фәнисә апа. – Әниебез 100гә җитсә дә, үз акылында. Матур итеп картайды. Бөтенебезне белеп, танып сөйләшә. Үз җае белән йөри, безгә киңәшләрен бирә. Озак яшим дип, әллә ниләр ашап, ниндидер күнегүләр ясап ятмый. Аллаһы Тәгалә аны озын гомер белән зурлаган. Әнием исә һәр туган көнгә рәхмәтле була белә. Әнә шуңа да озак яши инде ул. Әнием әле дә яшьлеген сагына. Кайчагында матур итеп җырлап та җибәрә. Инде үзебез олы яшьтә булсак та, әни янында шундый рәхәт. Без – һаман сабый әле!

Бер йөрәктә – мең ярату

«Ничек итеп ул сабыйларны ятимнәр йортына тапшырасың? Аллам сакласын!» Биектау районының Бөреле бистәсендә гомер итүче Фирая Мөбарәкшина нәселләрендәге авыру һәм ятим калган балаларны үз канаты астына җыя. Башта энесенең оныгын аякка бастыра. Хәзер инде улының авыру кызын һәм кызының ике улын тәрбияли. Үзенә дә 67 яшь инде.

– Гомерем буе үземне кызгануларын яратмадым, – дип башлады ул сүзен. – Минем язмышым башкаларга гыйбрәт булсын иде. Сабыйларны тәрбияләвем белән бик бәхетлемен мин. Әгәр шушы сабыйлар булмаса, ничек яшәр идем икән?

Фирая апа авырлыкларны күп күргән. Әмма аны сөйләп, күңелсезләнеп утыра торган кеше түгел. Тормыш сынаулары көчле иткән аны. Ире 46 яшендә йөрәк авыруыннан үлеп киткәч, туганының оныгы белән юанса, газиз кызының бакыйлыкка күчүен аның ятим калган балалары хакына күтәрә.

– Туганнан туган абыемның оныгы ятим калгач, миннән ул сабыйны үземә алуымны үтенделәр. Ул чакта үземнең улым һәм кызым буй җиткән иде инде. Ә абыем да, хатыны да сәламәтлеккә туена алмадылар. Аллаһка тапшырып, шул кызны үземә алып кайттым. Опека органнары да каршы килмәде, бирделәр, – ди ул. – Аннары улымның кызын да үземә алдым. Сабый авыру туды. Алар миңа иптәш булды. Ә мин үз чиратымда балаларга бар яратуымны, назымны бирдем.

Моннан өч ел элек Фирая апаның бар тормышының асты өскә килә. Матур гына гомер иткәндә, өч баласын ятим калдырып, кызы үлеп китә. Табиблар да ярдәм итә алмый үзенә. Аңа бары тик 38 яшь кенә була.

– Кызым беренче ире белән аерылышкан иде. Ул никахтан улы туды. Яңадан кияүгә чыгам, дигәч, мин оныкны үземә алып калдым. Үги әти янында кыен булмасын, дидем. Бар теләгем – кызымны матур яшәтү иде. Киявем дә яхшы кеше булып чыкты. Алар бик тату, бер-берләрен аңлап яши башладылар. Бер-бер артлы ике уллары туды, – дип сөйли Фирая апа. – Кызым еш кына ашказаны авыртудан зарлана иде. Гел, табибка күрен, дип әйтә килдем. Тик яшьләр сине тыңлыймыни соң ул? Хастаханәгә барырга ашыкмады. Кинәт авырып киткәч, соң иде инде. Балам «ашыгыч ярдәм» машинасында вафат булды. Ул үлгәндә, кечкенә оныкка 7 ай гына иде әле. 3 яшьлеген – мин, кечкенәсен кодагыем тәрбиягә алды. Тырышып-тырмашып, шул сабыйлар дип яшәп яту. Кодагыемны да кызганам. Кечкенә баланы үстерү җиңел түгел. Шөкер, аралашып яшибез. Балаларны бер-берләреннән аермыйбыз. Киявем дә улларын үстерергә каршы түгел иде. Төнлә эшләгәч, аңа авыр булмасын, дидек. Җитмәсә, башка шәһәрдә эшли ул. Аннары бит яшь тә әле ул. Ялгыз да яшәп булмый. Шуңа күрә кодагыем белән икәү оныкларны аякка бастырырга булдык. Шөкер, этиләре ташламый. Ялы булуга, шушы балалар янына килә. Үзенә дә алып китеп тора.

Фирая апа тормышы турында сөйләгәндә бер дә зарланмады. Арып киттем инде, дип тә әйтми. Киресенчә, Аллаһы Тәгалә шушы сабыйларны аякка бастырыр өчен көч һәм гомер бирсен иде, дип тели. Бала хәсрәте гомеремдә эчмәгән даруларны да эчертте инде, ди.

– Элек мин даруның ни икәнен дә белми идем. Ә хәзер кан басымы да уйнап куя кайчак. Әмма күңелемне төшермим. Хәсрәт килде дип елап ятарга ярамый. Паникага бирелү дә коткармый. Тормышка аек акыл белән карарга кирәк. Сабыйлар булгач, картаймыйсың да икән ул, – ди Фирая апа. – Тормышның яме – сабыйларда. Бер генә теләк: шул балаларны аякка бастыра алсам иде. Сәламәтлек кенә сорыйм Ходайдан. Калганын эшлим мин аның.

vk.com

«Шифа – догада»

Айдар кечкенәдән сәер төшләр күргән. Төшендә гел ак сакаллы бабай, аның янына килеп, догалар өйрәткән. Йокыдан торгач, бу хакта әти-әнисенә сөйләгән, әмма аңа ышанучы гына булмаган. Соңрак исә, кайбер күргән төшләре чынга аша башлагач, әйтеп куйган сүзләре кабул булгач, әти-әнисе Айдарның сүзләренең хаклыгына инана.

– Нәселебездә ерак әбиебез дә догалар белән кешеләр дәвалаган. Сәләтем шуннан күчкәндер, мөгаен, – ди Айдар Багитов. – Мин кешеләрне өшкерергә тотынгач, күз алдыма мәгълүматлар килә башлый. Әйтерсең фотолар карыйм. Кайчак аларны ни күрсәм дә җиткерәләр. Әмма күрәзәлек итәргә ярамагач, бу хакта дәшмим. Тик шулай да кешегә ипләп кенә, киңәш биргәндәй итеп әйтеп тә куям. Моны аларны кисәтү өчен әйтәм.

Айдар кешеләрне үз өендә кабул итми, чакырган җиргә үзе бара.

– Миңа күбрәк күңеленә тынычлык, тәненә сихәт таба алмаучылар мөрәҗәгать итә. Аларга күз тигәнне, бозык-сихерләре барлыгын күрәм. Күпләр, өшкерүемнең файдасын күрдек, дип рәхмәт укыйлар, – ди ул. – Кешеләр усалланды бит хәзер. Бер-берләренә юл куя белмиләр. Туган белән туган дус яшәми. Кешенең шатлыгына сөенмиләр. Ниндидер начарлык эшләргә тырышалар. Бозым ясаучыларның күбесе дә – үз якыннары. Әмма мин аларны берәүгә дә әйтмим. Кешеләргә дога укып ярдәм итә алам икән, шул җиткән. Доганың көче зур. Кайчагында укый гына башлыйм, елап җибәрүче дә бар, йоклап та китәләр.

Айдарны хәзерге заман балалары борчый. Баксаң, өшкертергә сабыйларын алып килүчеләр дә бар икән.

– Хәзерге балалар тыныч түгел. Алар башка төрле. Дөньяга карашлары бүтән. Икенче төрле уйлыйлар. Ә без, өлкәннәр, шуны кабул итә белмибез. Аннары инде аңлашылмаучанлыклар чыга. Бала үзен кирәксез дип уйлый. Үз тәҗрибәмнән чыгып шуны әйтә алам: аларда елдан-ел нерв авырулары артып бара, – ди Айдар. – Бер-берегне аңлап, ишетеп, тыңлап яшәргә кирәк. Тормышта авыр чакта да, җиңеллек килгәндә дә дога укыгыз. Беренче очракта җиңел булып китә, икенчесендә тормышыгыз тагын да яхшырып китәр. Ислам дине кушканча яшәсәк, күп кенә борчуларыбыз булмас иде. Үзегезне өшкертеп алу да кирәк. Бер генә теләк: кешеләр матур итеп, сөенеп яшәсеннәр, авырмасыннар иде. Тәннәре дә, күңелләре дә сау булсын.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

«ВТ» ГАЗЕТАСЫ 105 ЕЛЛЫККА ШӘХЕСЛӘР БЕЛӘН ӘҢГӘМӘЛӘР СЕРИЯСЕН БАШЛАП ҖИБӘРӘ.
БЕРЕНЧЕ КУНАК – ТАТАРСТАННЫҢ ҺӘМ БАШКОРТСТАННЫҢ ХАЛЫК, РОССИЯНЕҢ АТКАЗАНГАН АРТИСТЫ, ПРОФЕССОР САЛАВАТ ФӘТХЕТДИНОВ.

«КЕМ ИДЕК, КЕМ БУЛДЫК?»

Сәнгатьтә калып кирәк. Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров репертуары хәзер дә халыкка хезмәт итәргә тиеш. Продюсерлык файдагамы, зыянгамы? Авторларны кем якларга тиеш? Салават ФӘТХЕТДИНОВ белән шушы һәм башка бик күп сорауларга ачыклык керттек. Әңгәмәдәшебез үзен борчыган мәсьәләләр турында ачыктан-ачык сөйләште.

:: Сез – тәҗрибәле, ил агасы яшенә җиткән кеше. Татар матбугаты бик күп мәсьәләләрдә сезнең сүзне көтә. Әмма сез журналистларга бик ачык кеше түгел, бик сирәк кенә биргән интервьюларда да «мин журналистларны өнәп бетермим» дип әйтәсез. Моның сәбәбе нәрсәдә?

– Журналистларга булган мөнәсәбәт үзен әллә кемгә куеп сөйләшүчеләрдән чыгып, сиксәненче елларда формалашты. Хәзер аларның күбесе белән дуслаштык та инде. Минем күңелгә дә юл эзләргә кирәк. Журналист ул, беренчедән, миннән кимендә биш-алты тапкыр акыллырак булырга тиеш. Үземнән дә акылсыз кеше белән нәрсә турында сөйләшим? Кузгатсалар, күңелдәгесен әйтәм. Мәсәлән, «Үзгәреш җиле» буенча фикеремне әйттем, хәзер дә кабатлап әйтә алам. Миннән: «Бу конкурска кайчан да булса үпкәгез бетеп, катнашырга исәбегез юкмы?» – дип сорадылар. «Беркайчан да катнашмаячакмын!» – дип әйттем һәм катнашмаячакмын да. Чөнки ул татарга кирәкле юнәлеш түгел. Дөрес, минем үземнең дә эшләгән эшләрем күп түгел. Үз театрың белән ерак китеп булмый. Әмма эшләгәннәрем ояшырлык түгел. Ә кайчак кешенең эшләгән эше өчен оялам. Мин әйтәм, ник бу үзе ояла белми икән? Мин оялып утырам, алар оялмый. Хәзер инде сәнгатькә аңа бернинди катнашы, шул юнәлештә белеме булмаган кешеләр тыгыла. КХТИны тәмамлыйлар да, йә булмаса башка уку йортын, сәнгатькә кысылалар. Бу бит дөрес түгел! Шуңа күрә мин күп вакытта кул селтим. Бәлки, бу ялгыш гамәлдер, әмма бөтен нәрсәгә тавыш чыгарып та йөреп булмый. Ник дигәндә, оятсызлар күбрәк. Бер оятсызны җиңү өчен, кимендә ике акыллы кеше кирәк. Аның хәтле акыллыны каян табып бетерәсең?!

:: Нилектән шулай килеп чыга: халык үзе җиңеләйдеме, әллә әдәбият, мәдәният, сәнгать җиңеллеккә этәрдеме? Җиңеләя-җиңеләя, бөтен дөньябыз белән җиңеләеп бетмәбезме?

– Бер мисал. Беркөнне Дмитрий Певцов белән очраштык. Алар Майданов, Газманов белән Дәүләт Думасында бер проект белән чыктылар. Юкса, милли республика буларак, без чыгарга тиеш идек, әмма алар өлгерлек күрсәтте. Аларның рус теленең юкка чыга баруына, кибет исемнәренең, күп кенә башка атамаларның инглизчә аталуына эчләре пошкан. Бездә дә шул ук хәл бит. Әле әчтәләнгән дә аңлап бетермибездер. Мин һич югы атамаларның 50 проценты татарча булырга тиеш дип саныйм. Без бит – милли республика! Нилектән урамнарда татарча сүзләр күренми, күренсә дә, бик сирәк? Мөгаен, үзебез гаепледер. Беркемнең дә, татарча атамалар таләп итәбез, дип тавыш куптарганы юк бит әле.

> Элек худсовет бар иде. Ярый белән ярамыйны аеру өчен булырга тиеш ул. Мин, мәсәлән, туксанынчы еллардан башлап татар хатын-кызларын сәхнәгә чак кына киенеп чыгарга өйрәтергә тырышам. Ә, юк! Мин киендерәм, кемдер чишендерә.

Юнәлеш булмаганда, киенү рәвеше, әсәр эчтәлеге кебек мөһим әйберләр җуела. Бу җәһәттән тиздән закон проекты кабул ителәчәк. Аның нигезендә театрлар, мәсәлән, спектакльләрнең финалы Россия кануннарына яраклаштырылырга тиеш. Инде бит нәрсә куйганны да белми башладык. Нинди генә тәрҗемәләргә алынмыйбыз, кайчак аның бернинди мәгънәсе булмый. Азрак кына театрга, эстрадага икенче караш та булырга тиеш. Режиссерга нәрсә тели, шуны түгел, азрак кына киңәшләшеп эшләргә кирәк. Әнә бит Европа нинди сәясәт алып бара, имеш, егет белән кыз бер бәдрәфкә бара ала, егет белән егет, кыз белән кыз өйләнешә ала. Бу бит инде – кешелеклелек юкка чыкты дигән сүз. Күрә торып шуңа ризалашабызмы? Үрнәккә бер республика бар – Чечня. Ул киенү рәвеше, гаилә җәһәтеннән дә үрнәк.

:: Сез эстрадага, сәхнәгә дәүләт идеологиясен кертү турында сөйлисез. Бер яктан караганда, ул, бәлки, дөрестер. Икенче яктан цензура чикләүләргә китермәсме?

– Милләтнең үз йөзе, нинди дер бер калыбы булырга тиеш. Мөмкинлегем булса, мин әле сәнгатьне дә хоккейдагыча югары лига, беренче лига, икенче лига, дип бүлеп җыяр идем. Кайбер кагыйдәләргә искелек калдыгы дип карарга ярамый. Шул ук цензурага. Әгәр цензура булса, мәгънәсез җырлар чыкмас иде, кем нәрсә тели – шуны сөйләп тә йөрмәсләр иде. Цензура булмаса да, калып булырга тиеш. Киңәшләшеп эшләү булсын. Менә бу җырыңны алмаштырсак, ничек булыр иде дип, мәсәлән. Түзеп торырга ярамый бит инде. Илһам абый, Әлфия апа сәнгате хәзерге заманда юкка чыгып бара. Рифат Фәттахов әйткән бит инде, туксанынчы елга тиклем Ваһапов ясаган революциягә Салават туксанынчы елларда килеп бетерде, дигән. Мин моңа аптырамыйм. Кеше үзен журналистикада тапмагач, сәнгатькә килеп кергән, чөнки анда кем тели, шул бара ала. Без күреп алып, укытып, әзерләп биргән җырчылардан ул файда күрә. Без – бетерүчеләр түгел, дәвам иттерүчеләр, үстерүчеләр. Әгәр бу сүзне икенче кеше әйтсә, мин әле уйланыр идем. Чөнки абруйлы кешеләр сүзенә колак салам.

:: Татар эстрадасы төрле этапларны үтте. Инде хәзер нәрсә дә булса җырласын, татарча җырласын гына дигән чорга килеп җиттек. Моннан соң безне нәрсә көтә?

– Әлфия апа белән Илһам абыйның җырларын хөкүмәт тарафыннан сатып алып, ә алар күп түгел, кем тели – шуңа җырлатырга кирәк. Әйтик, Әлфия апаның кызы Зөлфия ирекле рәвештә бу җырларны бирми икән, Әлфия апа да, җырлары да онытылачак. Илһам абыйны да шул ук язмыш көтә. Кызык инде бу дөнья: Илһам абый исән чакта янында беркем дә юк иде, үлгәч, туганнары табылды. Акыллы булсалар, алар бу мирасны тыймаячак. Алар, җырлагыз, дисәләр, бөтен җырчы җырлаячак. Татар эстрадасында һәр җырчы репертуарының 50 проценты Әлфия апа, Илһам абый җырларыннан торачак. Ә сатып, судлашып йөрүгә калса, булмый. Менә минем Нияз Акмал сүзләренә язылган көчле бер җыр бар. Нинди сүзләр, нинди мәгънә анда! Шуны төшереп калдырдым. Чөнки каяндыр кызы килеп чыкты. Җырларга, шигырьләрен дөньяга чыгарырга рөхсәт юк. Әгәр автор, үзе минем иҗади мирас шушы кешегә кала, дип, үзе язып калдырмаган булса, аларны халыкка чыгарырга кирәк. Бу җәһәттән сәнгатьтә җәйга салынасы эшләрнең әле башы да күренми. Әле безнең күрәчәкләр, җырлар өчен судлашып йөрүләр алда.

:: Бу эш белән кем шөгыльләнергә тиеш соң?

– Менә без бер оешма төзедек. Мин – аның гамәлгә куючысы. Ул авторлык хокукын саклау буенча эш алып барачак. Бу мәсьәләдә Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәменә өметләнәм. Аның рәисе Марат Готыф улы Әхмәтов – татарның мәнфәгатен дә, кадерен дә белә торган шәхес. Әмма безнең оешма – яңа оешма, аңа каршы төшүчеләр дә булачак, дип уйлыйм. Беренче теләгем – Әлфия апа белән Илһам абый репертуарына кагылышлы кешеләрне чакырып, әлеге мирасны алардан сатып алу. Чөнки ул – татар милләтенең хәзинәсе. Шулай итсәк, Филүс Каһировның репертуары да әлеге җырлардан торачак, башкаларныкы да. Мин дә шуларны җырлаячакмын. Бүген мин Илһам абыйның бер җырын булса да җырларга куркам, чөнки законнары шундый: 20 җырның 19ына автор рөхсәте булып, 20 нчесенә булмаса, безне ач калдырачаклар. Зөлфия (Әлфия Авзалованың кызы. – **Ред.**) каршы булмас дип уйлыйм. Чөнки ул – төпле, фикерле кеше. Аның, нинди генә булса да, һәр фикере ихтирамга лаек, чөнки әнисен ахыргы көннәренәчә карады. Аның хакы бар, әлбәттә, әмма ул хокукны да дәүләт тарафыннан рәсмиләштереп була. Чөнки Әлфия апа белән Илһам абый хәзер дә милләткә хезмәт итәргә тиеш. Юкса, хәлләребез аяныч. Өч нота язалар да, сүзләре минеке, көе минеке, акча түләмим, диләр. Түләмәс өчен, әллә нинди мәгънәсез җырлар башкаралар. Аларны да аңларга була. Әле концертның бетеп тә җитми, сәхнә артына полиэтилен пакетларын тотып, РАОдан өч хатын килеп баса. Артист үзе бара, үзе оештыра, командасын үзе ашата, аның, әлбәттә, тапкан малын, тамагы белән эшләп алган акчасын бүлешәсе килми. РАО оешмасы исә акчаны җыя да Мәскәүгә җибәрә. Авторга, процентларын каергач, кире әйләнеп кайткан суммасы аз була. Без бу өлкәдә тәртип салырга әзер һәм риза.

:: Мәдәният министры киңәшчесе һәм Президент каршындагы мәдәният мәсьәләләре комиссиясе әгъзасы буларак, эстрада алдында торган төп проблеманы атасагыз иде.

– Барыбер дә дәүләт тарафыннан цензура кирәк. Җырларга теләгән бөтен кеше

дә сәхнәгә менәргә тиеш дигән сүз түгел. «Җырчы җаваплылыгы» дигән төшенчәне кире кайтару зарур. Иң аянычы – милли-лекне югалта барабыз. Әйтик, җырчыны үземә эшкә алам икән, аның репертуары, киенү рәвеше, тәртибе өчен мин җаваплы. Кызганыч, мәдәният гомере буе «калса, мәдәниятка булыр» принцибы буенча яшәде. Ә бит киресенчә булырга тиеш. Мәдәнияте булмаса, халык та юк.

Әйтәм бит, эшлисе эшләр шактый, шуңа безгә комиссия генә түгел, шушы юнәлештә эшли торган аерым бер министрлык кирәк.

:: Без – үзебез шундый пошмас милләтме, әллә шушы хәлгә китереп җиткерделәрме?

– Бу 10 гына ел, 20 генә ел, 50 генә ел барган сәясәт түгел. Шул ук вакытта бер әйтеп, бөтен нәрсәне үз урынына куйган милләтләр бар. Без бит – бер миллион гына түгел, без берничә миллионга җиткән халык! Безне диаспора дип карарга ярамый. Без – ил! Миңа калса, без үзебез гамьсез. Коръән буенча әйткәндә, битарафлык – үзе гөнаһ. Гафләт баскан безне. Менә шушы гафләттән котылырга кирәктер дип уйлыйм. Әйтәм бит, кулымнан килсә, милләтне саклау буенча тулы бер институт, министрлык төзер идем. Россиянең тотрыклылыгы Татарстан, Башкортстан кебек ныклы республикаларга бәйле.

:: Продюсерлар берлеге төзер идегезме соң?

– Күптән төзисем килә, ләкин мин бит әле эшли торган артист. Кем эшсез – шул берлекләр, бердәмлекләр төзи. Продюсер димәктән: бу өлкәдә иң арзанлы, иң мәгънәсез алымнар – Татарстанда. Ә рус эстрадасында хәлләр башкача. Анда продюсер җырчының репертуары, зәвыгы, килеш-килбәте һәм башка бик күп вак мәсьәләләр өчен дә җаваплы. Ул – бик зур нәрсә, аны чүп-чарга әйләндерергә ярамый. Ике-өч кеше җыелып, үзара вәкаләт бүлешүгә генә корыла торган нәрсә түгел ул. Киңәшләшеп эшләнә торган эш. Сайлау, сайлап куелу дигән нәрсә бар. Мин башка өлкәгә кысылмыйм, ә менә милләт өчен нәрсә кирәк, татар җырын саклау өчен нәрсә кирәк – анысын яхшы беләм. Шуның өчен укыдым һәм шуның өчен укытам.

:: Сез Филүс Каһиров иҗатын һәрвакыт бик югары бәялисез. Моның сере нәрсәдә?

– Филүс – безнең беренче номерлы җырчы, ул – эталон. Әмма Филүстән ун тапкыр түбәнрәкләр үзләрен аңардан югары куя. Менә бу тагын шул ук калыпсызлык бәласе инде. Сәнгать бер калыпка керсә, тамашачы да калыпка керер иде. Сертификат, лицензия, маршрут кәгазе – тәртипкә салуның ысуллары. Тәртип кирәк.

> Сәхнә тотучы кайберәүләрнең халыкны мишәрләргә, типтәрләргә бүлүенә дә мин каршы. Без – татарлар! Без – бөек халык! Менә шуны һичкайчан хәтердән чыгарырга ярамый, бүлгәләнү, бүлгәләргә тырышу беркайчан да юнылегә илтми. Халык артистның һәр сүзен чынга ала.

Шуңа күрә калып кирәк. Программаны да раслату кирәк. Бер тапкыр программаны худсовет алдында тапшыр да, йөр ел буе рәхәтләнеп. Бернинди куркыныч юк бит. Әйтик, бүген Салават Фәтхетдиновның худсовет алдында беренче концерты, дип игълан итсәләр, халык кызыксынып киләчәк. Иртәгә Илсөя Бәдретдинова, аннары башкалары булачак. Халык киләчәк. Ул бит – беренче концерт, яңа программа. Кая барасың – анысын да хәл итәргә кирәк. Кайчак бер шәһәргә бишәр төркем килеп төшә. Ул бер татар бит инде, аннары кайсына зал тула, кайсына тулмый. Талаш, үпкәләш китә. Маршрут биреп җибәрсәң, бу хәл килеп чыкмаячак бит. Әйтик, Самарада 5–6 артист эшли, Нижневартовскида берәү дә юк. Бу эштә контроль дәүләт тарафыннан булырга тиеш. Лицензия сатып алу да артык булмас.

> Хәзер нәрсә генә кыланмый җырчылар, сәхнәгә исереп чыгу да бар. Бу – татарга хас күренешме? Башка сыймаслык хәл бит. Бер тапкыр шундый хәлдә эләкте икән, лицензиясен алып тор. Дәвалангач чыгар сәхнәгә. Тамашачы бит исерек карарга килми, ул анда ял итәргә бара.

:: Үз шәкертләрегез өметләрегезне аклыймы, әллә кайберләре кызарырга да мәҗбүр итәме? Аерым алганда, Данир Сабиров иҗаты сезне сөендерәме, көендерәме?

– Данир – бик талантлы артист. Ул бик шәп юморист, көчле импровизатор. Ул җырчы буларак азрак чыгыш ясасын, күбрәк пародиягә урын бирсен дигән теләгем бар. Ул солист җырчы түгел, ул – юморист. Җырчыга караганда, күбрәк биюче. Мин аның барыбер күбрәк юмор өлкәсендә калуын теләр идем. Ә инде Рифат Зарипов юморны да, җырлауны да бертигез алып бара ала. Иң үкендергәннәре – Ландыш Хуҗиәхмәтова (Ләбибә), Айгөл Сәгынбаева. Шундый тавыш, шундый моң белән югалдылар. Укыткканда, кызларга шаярып әйтә торган сүзем бар иде: сезнең бурыч – «удачно» кияүгә чыгу. Әллә шаярып әйтеп, үзем дөньяны бутадым: кияүгә чыгалар да харап булалар. Хатын-кызга, син матур җырлыйсың, кияүгә чыкма, дип әйтеп булмый бит инде. Аңа тормыш кору ир кешегә караганда ун тапкыр авыррак. Без бит хатыннарны алабыз, кызлар чыгалар. Алмасаң, чыгып булмый бит. Шуңа күрә аңа сәнгатьтә бигрәк тә авыр. Я аның ире бу өлкәдә эшләвенә риза булырга тиеш, я бу өлкәдән китәргә кирәк. Кич белән кайтып, талашып яши торган профессия түгел бу. Әйтәләр бит, өйдә я ике артист булсын, я бер дә булмасын, дип. Ул бик дөрес. Артистны артист кына аңлый.

:: Гаилә – сезнең өчен нәрсә ул?

– Мин балаларны тәрбияләүдә әллә ни катнашмадым. Гомерем гастрольдә үтте. Әмма барыбер мин алар өчен авторитет булдым. Мин алардан бер генә нәрсә таләп иттем: күңелемне сындырмасыннар. Баланың ата-ана күңелен сындырырга бөтенләй хакы юк. Әгәр ул шуны эшли икән, димәк, анда өмет юк. Тормышта төрле хәлләр була, аңлашылмаучанлыклар килеп чыга. Әмма һәр нәрсәне аңлашып хәл итеп була. Безнең өйдә шулай куелган: ял көннәрендә барыбыз да бергә җыелабыз. Балалар, оныклар, килен-кияүләр безгә килә. Бу – шундый тәртип, шундый кагыйдә.

:: Әниегез янына кайтып йөрисезме?

– Әнигә – 92 яшь, авыр инде аңа, җанкисәккәемә. Инде дүрт елдан артык урын өстендә. Ул энекәш тәрбиясендә яши. Мин мөмкинлегем булганда кайтырга тырышам. Янына килеп ятам да сөйләшәбез. Кунып китсәм, шатлана, көнендә китсәм, борчыла. Көнгә бер мәртәбә «Ватсап»тан сөйләшергә өйрәндек. Бүлмәсенә камера да куйдык, кайчан телим, шунда карап, хәлен беләм. Иң авыры – караган кешегә. Бернишләп тә булмый инде. Әни исән, ул исән булгач, мин – бала. Миңа гыйнварда 63 яшь тула, мин – әле дә бала, Аллага шөкер.

:: Күңелегезне аңлар кешеләр күпме?

– Аллага шөкер, минем тирәмдә йөргән дистәләгән кешедән котылдым. Дус дип әйтергә ярамый аларны, яхшы танышлар дип әйтик. Ә чын дуслар күп булмый. Ул я бер, я бер ярым була. Икәү булса, алар бергә кушылып, миңа каршы эшли башлыйлар. Мин башта аны аңламый идем, хәзер төшендем. Инде шушы ук сүзләрне улым Рөстәмгә әйтәм, зирәк булырга өйрәтәм.

:: «Ак барс» командасының быелгы уеннары турында ни әйтерсез? Җиңүгә ирешү мөмкинме? Төп ялгыш нәрсәдә булды?

– Быелгы сыман «Ак барс»тан өметне өзгән юк иде. Мондый оятлы хәлдә беренче ел. КХЛ ачылганнан башлап, өч тапкыр Гагарин Кубогы алган команда болай итеп үз республикасыннан көләргә тиеш түгел. Мин ярыш карарга даими барам, җиңеләселәрен белеп барам. Борчылмыйм да, соңгы вакытта гел җиңелсеннәр иде, мин әйтәм. Ни өчен: бер җиңеп, бер җиңелеп барса, бер нәрсә үзгәрми. Җиңелгәч, ахыргача җиңелегез дә инде, плей-оффтан төшеп калыгыз да, аннан соң, бәлки, состав үзгәрер, икенче караш булыр. Беткәч, бетсен генә инде.

Мин команданың системасыннан канәгать түгел. Әйтик, спортчы белән төзелгән фәлән миллион сумлык контракт. Ул, җиңелсә дә, шушы акчаны ала, җиңсә дә. Нәрсәгә борчылсын соң ул? Без – ун мең татар борчылып, акырып, елап утырабыз, ул борчылмый. Ә инде, җиңсәгез, шуның чаклы аласыз, җиңелсәгез, шул чаклы, дисәләр, бөтен системасы үзгәрәчәк.

Әле шушы көннәрдә генә Зиннәтулла Билалетдинов яңадан «Ак барс»ка кайтты. Моңа шатлануымның иге-чиге юк. Күңелем тынычлык тапты, киләчәккә өмет артты.

:: Безнең халыкта спортны аңлау бармы? Рөстәмне спортчы буларак танныйлармы?

– Рөстәм автоспорт кагыйдәләрен яхшы аңлый. Әгәр сине яратмыйлар, синнән куркалар икән, димәк, сине спортчы буларак таныганнар. Рөстәм сер бирми. Аның спортка кереп китүе ир-егетләрчә тәрбия алсын, чыныксын дигән теләктән башланды. Җиңү бер нәрсә, җиңелергә дә өйрәнсен, вакытында китә белсен. Минем өчен иң шатлыклы вакыйга – аның 20 яшендә тренер хезмәтенә алынуы. Ул Грозный шәһәрендә балалар белән шөгыльләнә. Балалар үзләре аны сайлаганнар. 20 яшьлек тренер тарихта юктыр, мөгаен. Горурланам. 12 яшендә, юниорлар арасында җиңә башлаган иде, 17 яшендә зурлар арасында чемпион булды. Быел ике алтын, бер көмеш медаль яулады. Андый спортчылар бик сирәк. Әмма барыбер ул спортны хобби буларак кабул итәргә тиеш. Белем алырга, укырга кирәк.

:: Соңгысы итеп, сезгә фәлсәфи сорау: без әле кая барабыз?

– Бу – иң авыр сорау. Моңа җавап бирер өчен кимендә 100 ел артка чигенергә, һич югы 10 ел алга барып фикер йөртергә кирәк. Без кем идек – без кем булдык? Шушы сорау җавап булыр кебек. Мин бер нәрсәгә генә өметләнеп яшим: тарих кабатланырга ярата. Кайчан да булса татарның кирәклеген, татарның зирәклеген аңларлар. Без тырыш, без булган, без – моңлы, итагатьле милләт. Дөрес кылмаган гамәлләребезне вакытлыча ялгышлык дип исәплим.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА язып алды

ВИДЕО VATANTAT.RU САЙТЫНДА

chelny-izvest.ru

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның
беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язылу

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘККӘ
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

П2435
жомга саны
512 сум 70 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+ реклама

Әз-мәз мәзәк

«Ашыгыч ярдәм» – 03. Әмма кайберәүләр өчен – 0,5 яки 0,75.

* * *

Китап кибетендә:
– Сездә «Хатын-кызларның аңлаешлы психологиясе» дигән китап бармы?
– «Фантастика» дигән киштәдән эзләп карагыз әле.

* * *

Менә күрәсезме, берни эшләмәдек һәм хаталар өстендә эш тә эшлисе юк.

* * *

Мин элек стоматологның бормашинасыннан курка идем. Хәзер бәяләреннән куркам.

* * *

Әгәр дә хатыныгыз сез бүләк иткән чәчәк бәйләмен социаль челтәргә элмәгән икән, димәк, ул – арзанлы чәчәк бәйләме.

31 ДЕКАБРЬГӘ КАДӘР ӨЛГЕРӘСЕ!

- Быел эшләп бетерәсе эшләрне тәмамларга.
- Кемнәргә бүләк аласын исемлек итеп төзергә.
- Бүләк алуларны соңгы көнгә калдырмаска.
- Яңа елны кайда каршылыйсын алдан уйларга.
- Сәфәргә җыенсагыз, билетларны алдан алырга.
- Барлык кешеләрне гафу итәргә һәм гаебегез булса, гафу үтенергә.
- Әҗәтләрне мөмкин кадәр түләп бетерергә.
- Өйне җыештырырга, чүп-чарны чыгарып атарга.
- Елга анализ ясарга һәм киләсе елга планнар корып куярга.
- Бәйрәм кәефе булдырырга һәм аны мөмкин кадәр озак сакларга.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: сала, Бишнә, шулпа, рейх, Хәлим, Анна, Ясин, ант, скутер, Данил, ион, ир, ымлык, ел, максат, Әдрән, Халисә, Әмири, хаҗ, махмыр, әби, ил, пи, бәби, Ли, аспирант, тай, Итле.

Вертикаль: Идегәй, әйбәт, Александр, та, Рәхимбай, ашханә, ис, Си, Нәҗип, Яланаяклы, мә, Лилия, Хим, Бах, теләк, ара, Салих, ни, шәл, рикша, ТТ, тастымал, Әхмәтҗанов, исе.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Беләсең килсә...

1 Фәнни телдә Cucumis sativus дип аталучы яшелчә ул...
а) кабак;
б) томат;
в) кыяр.

2 Россия футбол җыелмасы дөнья чемпионатында ничә тапкыр чыгыш ясаган?
а) 3;
б) 4;
в) 5.

3 Иосиф Сталинның улы Василий Казанда кайсы урамда яшәгән?
а) Бауман;
б) Гагарин;
в) Ленин.

4 Гоголь әсәрендә Тарас Бульбаның ничә улы булган?
а) 2;
б) 3;
в) 4.

1. в); 2. б); 3. б); 4. а).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 390

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булырак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+